ПРЕЗИДЕНТ СҮЗЕ

Владимир Путин Федераль Җыенга еллык Юллама белән мөрәҗәгать итте. Алда безне ни көтә?

> 2

РИММА ИБРАҺИМОВА:

«Тамашачы ул күзгә түгел, аның алдында бурычлы торырга кирәкми»

> 18

ЗИННӘТУЛЛА ҺӘМ КОМАНДАСЫ

«Ак барс» Гагарин Кубогы өчен көрәштә «Автомобилист»ка каршы уйный

> 19

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 27 (29187) | Җомга | 1 март | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

АВЫЛ ТОТКАЛАРЫ

МИЛЛӘТ АЛГА БАРСЫН ӨЧЕН ЭШ КИРӘК

Авыл һәм милләт таянычы. Ничек кенә купшы яңгырамасын, аларның эшчәнлеген тасвирлаганда шуннан да кулайрак сүзләр табып булмас кебек. Татар авыллары эшмәкәрләре мәчет, мәктәпләр салдыра, яше-картына булыша, татар телен саклау, рухны, иманны ныгыту, яшьләрне туган җирләрендә калдыру юнәлешендә зур эшләр башкара.

4–6 март көннәрендә милләттәшләребез кабат Казанда җыела. Бу юлы алар Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре җыенына киләләр. Уникенче тапкыр оештырылучы җыен Россиянең иллегә якын төбәгеннән 800 татар эшмәкәрен бер мәйданда очраштырачак. Очрашудан нинди нәтиҗәләр көтәргә? Эшмәкәрләрнең уй-ниятләре нинди? «ВТ» хәбәрчеләре җыен алдыннан шул сорауларга җавап эзләде.

> 4–7

Ишетми калмагыз

Быел Татарстанда илкүләм проектларны гамәлгә ашыру кысасында 286 социаль, юл челтәре объекты төзеләчәк һәм төзекләндереләчәк.
2024 елда республикада 13 илкүләм проектка керүче 49 төбәк проекты гамәлгә ашырыла. Моның өчен 25,8 миллиард сум каралган. Бу акча югарыда телгә алып үтелгән максатка тотылачак.
«Россиядә сәламәтлек саклау өлкәсенең беренчел буынын яңарту» төбәк проекты буенча 128 дәвалау оешмасы объектын төзү һәм капиталь төзекләндерү күздә тотыла. Татарстанга быел «Сәламәтлек» илкүләм проектын тормышка ашыруга 3,5 миллиард сум юлланачак.

Татарстанда 15–17 мартта Россия Президентын сайлауга 21,6 мең участок сайлау комиссиясе әгъзасы җәлеп ителәчәк. Республика Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе Андрей Кондратьев әйтүенчә, шуның 7,5 меңе – укытучы, 600е – табиб, 200дән артыгы – эшмәкәр һәм студент. Хәзер алар әлеге мөһим чарага әзерләнә. Моннан тыш сайлауда 10 меңнән артыграк иҗтимагый күзәтүче катнашачак. 2021 елда республикада сайлауга 17 мең күзәтүче җәлеп ителгән булган. Асылда бу – күңел кушуы буенча йөрүче яшьләр.
Сайлауга 4 кандидат: бүгенге дәүләт башлыгы Владимир Путин (үзен үзе тәкъдим итүче буларак), «Новые люди» партиясеннән Владислав Даванков, ЛДПРдан Леонид Слуцкий һәм КПРФтан Николай Харитонов кертелде.

Ел башыннан бирле Татарстанда 69 кеше кызамык белән чирләгән. Татарстан баш санитар табибы урынбасары Любовь Авдонина әйтүенчә, бу узган елның шушы ук чорындагыга караганда күбрәк. Чирләүчеләрнең 22 проценты – чит илдән килүчеләр. 60 проценты чамасы вирусны башка төбәкләрдән ияртеп кайтуларын әйткән. Сырхауларның 8е генә авыруны Татарстанда йоктырган. Исегезгә төшерәбез: гыйнвар ахырында Роспотребнадзор идарәсе республикада кызамыкның бик нык таралуы турында кисәтте.

Бу атнада – 2–3 мартта республика антициклон йогынтысында кала: алмашынучан болытлы һава, явым-төшем көтелми. Һава температурасы көндезге сәгатьләрдә урыны белән «плюс»ка үзгәрәчәк.
Шимбә – 2 мартта көндез термометрның терекөмеш баганасы –3...+1 күрсәтәчәк. Төнге һәм иртәнге сәгатьләрдә –5...–11 градус. Якшәмбе – 3 мартта көндез 0...–5, төнлә –7...–12 градус тәшкил итәчәк.
Гидрометеоүзәкнең башлангыч мәгълүматларына караганда, киләсе атна башында – 4–5 мартта көндез һава температурасы –3...+1 градус чикләрендә тирбәләчәк. Төнлә температура –7...–12, урыны белән –18 градуска кадәр төшәчәк.

ЗУР ГАИЛӘНЕҢ КИЛӘЧӘК ЮЛЫ

ВЛАДИМИР ПУТИН ИЛНЕҢ ҮСЕШ НОКТАЛАРЫН БИЛГЕЛӘДЕ

kremlin.ru

Гаиләләргә ярдәм, Ватан сагында торучылар белән горурлану һәм биш яңа илкүләм проект. Россия Президенты Владимир Путин Федераль Җыенга еллык Юллама белән мөрәҗәгать итте. Быелгы иң озын чыгышның күп өлеше илнең эчке сәясәтенә, бигрәк тә социаль һәм хәрби тармакларга багышланды. Илбашы алдагы алты елга бурычлар билгеләде. Юлламада яңгыраган төп фикерләрне сезгә дә тәкъдим итәбез.

Махсус хәрби операция турында

Без сезнең белән иң авыр мәсьәләләрне дә хәл итә алуыбызны, теләсә нинди, иң авыр сорауларга да җавап табуыбызны раслап күрсәттек инде. Россиядә яшәүчеләрнең күпчелеге махсус хәрби операцияне хуплады. Сәнәгать предприятиеләре өчәр сменада – фронтка күпме кирәк булса, шулкадәр эшли. Халык фронтка хатлар, посылкалар, җылы киемнәр, маскировка челтәрләре, болай да зур булмаган маяларыннан акча юллый. Мондый ярдәм бәяләп бетергесез. Бу – һәркайсыбызның уртак җиңүгә керткән өлеше. Алга таба да ил эчендәге вазгыятькә тыкшынырга мөмкинлек бирмәячәкбез. Без, Россия гражданнары, ирегебезне, тыныч һәм лаеклы тормышка хакыбызны бергәләп яклаячакбыз һәм үзебез, фәкать үзебез киләчәк юлны сайлаячакбыз.

Бу сугышны без башламадык, әмма аны тәмамлау өчен барысын да эшләячәкбез.

Гаиләләргә ярдәм турында

Гаиләнең төп максаты нәселне, бөтен халкыбызның киләчәген дәвам иттерүдән гыйбарәт. Алдагы алты елда илдә туучылар санын арттыру бурычы тора. Демографиягә икътисад һәм социаль өлкәдәге вазгыять кенә тәэсир итми. Бөтен хакимият органнарының эше мөһим. Балалы гаиләләргә ярдәм итәргә кирәк. 2030 елга кадәр исәпләнгән «Гаилә» илкүләм проекты кысасында, туучылар саны аз булган ил төбәкләренә өстәмә матди ярдәм дә каралган.

Ишле гаилә гадәти күренешкә әверелергә, тормыш фәлсәфәсе булырга тиеш.

Аларга ярдәм итү йөзеннән, салым чигерүен икенче балага – 2800 сум, ә өченче һәм аннан соңгы балага 6000 мең сумга кадәр арттырырга тәкъдим итәм. Шул рәвешле, өч балалы гаилә бюджетында ай саен 1300 сум акча янга калачак. Ана капиталы, «Гаилә ипотекасы» һәм гаиләдә туган өченче балага ипотека бурычын каплау хисабына 450 мең сум акча түләү программаларын да 2030 елга кадәр озайтырга тәкъдим итәм. Бүген ил халкының 9 проценты фәкыйрьлекнең теге ягында яши. Шул исәптән ишле гаиләләрнең 30 проценты ярлы булып санала. 2030 елда без әлеге күрсәткечләрне 7 һәм 12 процентка кадәр җиткерергә тиеш.

Халыкның сәламәтлеге турында

Соңгы елларда илдә даими рәвештә спорт белән шөгыльләнүчеләр саны артты. Үз сәламәтлеген кайгыртучыларга кызыксындыру чаралары булдырырга кирәк. Киләсе елдан ук даими рәвештә диспансеризация узучыларга һәм ГТО нормаларын уңышлы тапшыручыларга салым чигерүләрен гамәлгә кертәчәкбез. Эчүне ташла да чаңгыга бас, дигән мәзәкне күбебез хәтерли бит. Сүз уңаеннан, илдә хәмер, бигрәк тә каты исерткеч эчемлекләр куллану күрсәткече кимеде. Бу исә милләтнең сәламәтлегендә дә чагыла. Федераль чаралар хисабына ил төбәкләрендә, бигрәк тә кечкенә шәһәрләрдә, авыл җирлекләрендә өстәмә рәвештә ел саен кимендә 350 спорт объекты төзергә тәкъдим итәм.

2030 елга илдә уртача гомер озынлыгын – 78, ә алга таба – 80 яшькә кадәр җиткерү бурычы тора.

Балалар бакчалары һәм мәктәпләр турында

Киләсе елдан балалар бакчаларын капиталь төзекләндерү программасын башлыйбыз. Чөнки бу биналарның күбесе совет чорында ук төзелгән һәм яңартуны таләп итә. Халык үзе дә шуны сорый. Мәктәпләргә килгәндә, 18,5 меңгә якын бинаны капиталь төзекләндерергә кирәк.

2030 елга кадәр илнең барлык төбәкләрендә дә моңа бәйле проблеманы хәл итеп бетерергә булышачакбыз. Ә алга таба бу эшне планлы рәвештә эшләячәкбез.

Юлламадан аңлашылганча, бу ел азагына кадәр илдә яңа биш илкүләм проект расланып бетәргә тиеш. Алар – «Гаилә», «Кадрлар», «Озак һәм актив тормыш», «Россия яшьләре» һәм «Мәгълүмат икътисады» («Экономика данных») илкүләм проектлары.

Гомумән алганда, балалар бакчалары һәм мәктәпләрне капиталь төзекләндерүгә генә дә 400 миллиард сумнан артык акча тотылачак. Моннан тыш, алдагы алты елда мәктәпләрдә медицина кабинетлары ачарга, булганнарын яңартырга тәкъдим итәм. Бүген уку йортларының 65 процентында гына мондый бүлмәләр бар.

БДИ турында

Укыту программасы камил һәм уйлап эшләнелгән булырга тиеш.

Мәктәптә бер нәрсәгә өйрәтеп, имтиханда гомумән икенче нәрсә таләп итү файдага түгел, әлбәттә. Бүген әнә шундый хәлләр дә очрый. Ахыр чиктә, әти-әниләр репетиторлар ялларга мәҗбүр. Тик бөтен гаиләләрнең дә мондый мөмкинлеге юк бит. Шуңа күрә бу мәсьәләне ачыклап бетерергә киңәш итәм. Шул ук БДИ да җәмәгатьчелектә күп сораулар уята. Мин чыгарылыш сыйныф укучыларына үз теләкләре буенча, бер БДИны яңадан тапшыру хокукын бирергә тәкъдим итәм.

Хезмәт хакларын арттыру турында

2024 елның 1 сентябреннән мәктәпләр һәм көллиятләрдә директорларның тәрбия эшләре буенча киңәшчеләренә ай саен 5 мең сум күләмендә яңа федераль түләү кертергә тәкъдим итәм. Бу моңарчы юк иде. Моннан тыш, 1 марттан халык саны 100 меңнән артмаган кечкенә шәһәрләрдә һәм торак пунктларда урнашкан мәктәпләрдә һәм көллият-техникумнарда белем бирүче сыйныф җитәкчеләренә һәм төркем кураторларына гамәлдәге федераль түләүне ике тапкыр арттырып, 10 мең сумга җиткерергә кирәк. Хөкүмәттән 2025 елга кадәр бюджет тармагында эшләүчеләргә хезмәт хакы түләүнең яңа моделен булдыруларын, ә 2026 елда аны кабул итүләрен сорыйм.

2030 елда илдә хезмәт өчен түләүнең минималь күләме ике тапкыр диярлек артып, 35 мең сумга җитәргә тиеш.

Илдә Саклык сертификаты да барлыкка киләчәк. Ул акчаны кредит оешмасына өч елдан да күбрәк вакытка салып куюны күздә тота. 2,8 миллион сумга кадәр акча иминиятләштереләчәк.

Бизнес турында

Россия бизнесына капиталны саклауның иң ышанычлы юлы ул – көчле һәм

мөстәкыйль илебез. Акчаны төбәкләргә, компанияләр үсешенә, кадрларга юнәлтергә кирәк. Катгый таләп: ил бизнесы үзебезнең юрисдикция кысасында эшләсен, акчаны читкә җибәрмәсен. Югыйсә бөтен байлыкны югалтырга да мөмкинсең икән бит. Бүген кайбер эшкуарлар белән чит илдәге акчаларын кире кайтару юллары турында уйлыйбыз. Анда җибәрмәгез – кире кайтарасы да булмаячак.

Россиядәге бизнес якланган булырга тиеш. Бу ил өчен дә, җәмгыять өчен дә кирәк.

Беркемнең дә кешене кысрыклау яки законнарны үз файдасына куллану хокукы юк. Эшкуарларга ярдәм итик. 2025 елдан, шик булмаган очракта, тикшерүләр санын киметергә тәкъдим итәм. Шулай ук, зур булмаган бизнеска, кредит тарихын бозмыйча, елга бер тапкыр алты айга кредит каникулы бирик.

Төбәкләр үсеше турында

Ил төбәкләренең бурычка бәйле йөген киметергә кирәк.

Шуңа күрә аларның бюджет кредитына бәйле бурычларының өчтән ике өлешен сызып ташларга тәкъдим итәм. Бу төбәкләргә 2025–2028 елларда ел саен 200 миллиард сумга кадәр акчаны янга калдырырга булышачак. Аны максатчан рәвештә урыннардагы инвестиция һәм инфраструктура проектларын тормышка ашыруга тотсыннар.

Мәдәният өлкәсе турында

Алдагы алты елда ил күләмендә 30 меңнән артык җәмәгать урыннарын төзекләндерәчәкбез.

Болар – элеккеге биналар, утарлар, гыйбадәтханәләр, ягъни буыннар бәйләнешенең чагылышы. 2030 елга кадәр меңләгән мәдәни мирас объектын тәртипкә китерергә кирәк. Мәдәният өлкәсендәге проектларны финанслауны алга таба да дәвам иттерәчәкбез. «Пушкин картасы»н да киңәйтергә кирәк дип саныйм. 2025 елдан «Авыл табибы» программасы кебек үк, «Авыл мәдәният өлкәсе хезмәткәре» программасы башланачак. Авылга эшкә кайткан белгеч бер тапкыр 1 миллион сум күләмендә түләү алачак. Ерак Көнчыгыш, Донбасс һәм Новороссиядә ул 2 миллион сум тәшкил итәчәк.

Транспорт өлкәсе турында

Җәмәгать транспорты тармагын яшәртәчәкбез. Моның өчен ил төбәкләренә өстәмә рәвештә 40 мең транспорт чарасы бирелəчәк. Үзебездә җитештерелгән очкычлар хисабына һава паркын да яңартырга кирәк.

Бу – катлаулы бурыч, читтән бик күп сатып алганбыз, ә үзебезнең сәнәгатьне үстермәгәнбез.

Ничек кенә булмасын, илдәге алдынгы эшләнмәләр югары тизлекле тимер юл челтәрен төзегәндә дә кирәк булачак. Тәүге маршрут Тверь һәм Бөек Новгород аша Мәскәүдән Санкт-Петербургка салыначак. Аннары Казан, Урал, Кара диңгез яр буе, Минск кебек башка юнәлешләр буенча да эшләячәкбез.

Яңа кадрлар программасы турында

Мин махсус хәрби операциядә катнашучылар белән еш очрашам. Алар барысы да Ватаныбызны яклый. Алар артка чигенмәячәк, хыянәт итмәячәк. Бу кешеләргә карагач, йөрәк горурлык хисе белән тула. Минемчә, нәкъ менә шундый кешеләр югары вазыйфаларны биләргә, төбәкләрне җитәкләргә, остазлык белән шөгыльләнергә тиеш. Аларга илнең киләчәген ышанып тапшырып була. Шуңа күрә махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм ветераннар өчен бу елның 1 мартыннан махсус кадрлар программасы башланачак. Аны «Каһарманнар заманы» дип атыйк. Махсус хәрби операциядә катнашучылар илебезнең иң яхшы вузларында белем алу мөмкинлегенә ия булачак. Гаризаларны иртәгәдән үк тапшырырга мөмкин.

Без – бер зур гаилә һәм үзебез ничек телибез, шулай эшләячәкбез. Мин Россиянең киләчәгенә ышанам!

Эльвира ВӘЛИЕВА

Владимир Путинның Федераль Җыенга быелгы Юлламасы иң озыны – ул **2 сәгать 6 минут** дәвам итте. Былтыр Илбашы **1 сәгать 45 минут** чыгыш ясаган иде. Вакыт ягыннан иң кыска Юлламалар 2004 һәм 2005 елларда **(48 минут)** яңгырады.

Мөнәсәбәт

Сәрия САБУРСКАЯ,
Татарстанда Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил:
– Президент үзенең чыгышын бүген Ватан сагындагы хәрбиләрнең барчасына, аларның гаиләләренә карата ихтирам сүзләреннән башлап җибәрде. Бүген хәрбиләр һәм аларның гаиләләре өчен бик күп ярдәм чаралары гамәлдә. Алар алга таба тагын да күбәергә мөмкин. Владимир Владимирович иң элек быелгы Юлламасының үзенчәлекле булуын, аның нәкъ менә илебездә яшәүчеләр белән очрашулардан чыгып булдырылуын билгеләп үтте. Халыкның ихтыяҗларыннан чыгып төзелгән план дип бәяләргә мөмкин аны. Бу ихтыяҗларның ишетеләчәгенә, проблемаларның хәл ителәчәгенә, яңа ярдәм чараларының, һичшиксез, булдырылачагына ышанам.

Айрат ФӘРРАХОВ,
Россия Дәүләт Думасы депутаты:
– Бик көчле Юллама булды. Киләчәккә үсеш юллары билгеләнде. Ул иң беренче чиратта бәйсезлекне, икътисад үсешен күздә тота. Гаиләләргә, авыл җирлеге, төбәкләргә ярдәм йөзеннән бик күп чаралар күреләчәге сөендерә.

Гөлшат НИГЪМӘТУЛЛИНА,
Татарстан Министрлар Кабинетының ЗАГС идарәсе башлыгы:
– Әлеге Юллама ил үсеше өчен хәлиткеч. Президент озак вакытка исәпләнгән стратегик бурычлар куйды. Гаилә, демография, яшьләргә, күпбалалы гаиләләргә ярдәм, белем алу өчен шартлар булдыру, илнең фәнни-технологик үсеше мәсьәләләренә басым ясады. Болар – Россия икътисадының нигезен булдыручылар. Ул моннан алдагы елларда да гаилә темасы турында гел әйтеп килде. Ләкин быел «Гаилә» илкүләм проекты барлыкка килү турында әйтелде. Ул халыкның барлык катлауларын да колачлый. Моны тормышка ашыру өчен, әлбәттә, без барыбыз да тырышырга тиеш, чөнки гаилә ул – илнең төп нигезе. Үзеңне ышанычлы, җәмгыять өчен кирәкле кеше итеп тоюда гаиләнең дә өлеше зур.

Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН,
Татарстан мөфтие:
– Президент Юлламасында Россия халыкларының бердәмлеге, Евразия һәм гарәп дәүләтләре белән хезмәттәшлек, традицион кыйммәтләр һәм гаилә, хәмер эчүнең кимүе турындагы сүзләр игътибарымны аеруча җәлеп итте. Илебез башлыгы авызыннан милли мәсьәләләр хакындагы кирәксез һәм урынсыз бәхәсләргә нокта куярлык сүзләр яңгырады. Ул: «Христианнар һәм мөселманнар, яһүдиләр һәм буддистлар, төрле мәдәният вәкилләре иңгә-иң уртак Ватан өчен көрәшә», – диде. Ягъни Россия – гасырлар буена бергә яшәгән төрле халыклар өчен уртак йорт булып тора. Моннан тыш, Владимир Владимирович тагын бер кат мөселман илләре белән бәйләнешләрдә зур перспективалар барлыгын раслады. Димәк, Татарстанның бу юнәлештәге эшчәнлеге бик вакытлы һәм актуаль. Гаилә кыйммәтләрен саклау һәм демография проблемалары турында күп сөйлибез, ә Президент аларны хәл итү буенча бик кирәкле тәкъдимнәр белән чыкты. Мөселманнар арасында күпбалалы гаиләләр шактый, шуңа күрә бу тәкъдимнәр аларны куандырыр, дип уйлыйм. Президент Россиядә хәмер эчүнең кимүе турында хәбәр итте. Аллаһка шөкер! Дәүләт дәрәҗәсендә бу проблеманы дөрес аңлыйлар икән, дигән нәтиҗә чыгардым.

Евгения КОЦАРЬ,
«Җиңү өчен! Казан» гуманитар ярдәм хәрәкәте оештыручысы:
– Гуманитар ярдәм хәрәкәте җитәкчесе буларак, махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм итүгә күп көч куйган волонтерларга, хәйрия оешмаларына рәхмәт әйтүе дә күңелемә хуш килде. Владимир Путин: «Суверен, нык Россиядән башка дөньяда тәртип була алмый», – диде. Аның белән тулысынча килешәм. Бай тарихлы көчле дәүләт бәхәсләр куерган чорда да бу сынауны лаеклы рәвештә узарга, җиңәргә тиеш. Президент махсус операциядә катнашучыларның беркайчан да хыянәткә бармаячагын, аларга Россияне курыкмыйча ышанып тапшырып булуын да искәртте.

Асия ТИМИРЯСОВА,
Казан инновация университеты ректоры, Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет рәисе:
– Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет рәисе буларак, миңа Президентның, чыгарылыш сыйныф укучыларына БДИдан бер фәнне яңадан тапшырып карау мөмкинлеген бирергә кирәк, дигән сүзен ишетү бик мөһим иде. Ни өчен дигәндә, без укучыларның психологик, шулай ук төрле сәбәпләр аркасында имтиханнарны уңышсыз бирү очракларын беләбез. Андыйлар вузга бары бер елдан соң гына укырга керә ала. Бу сорауга Владимир Путин аталарча якын килеп, укучыларга бер имтиханны кабат тапшыру мөмкинлеген бирде. Әлеге яңалыкны әти-әниләр, укучылар, укытучылар да бик шатланып кабул итәр. Бу карарны алар күптән көткән иде.

Динар БАРИЕВ,
Дәүләт Советы депутаты, «Алдынгылар хәрәкәте»нең Казан бүлеге җитәкчесе:
– Яшьләр вәкиле буларак, Президент Юлламасында минем өчен иң мөһиме «Россия яшьләре» илкүләм проектын башлап җибәрү булды. Әгәр моңа кадәр яшьләр мәнфәгатьләре төрле илкүләм проектларда тәкъдим ителгән булса, хәзер аерым проект бар. Гомумән, Юлламада яшьләр, гаилә, һөнәри белем һәм әзерлек мәсьәләләренә зур урын бирелде. Президент яшьләр сәясәте инфраструктурасы, социаль хезмәтләрне үстерү тенденциясенә аерым тукталды. Миңа калса, бик дөрес һәм акыллы карар. Бигрәк тә Гаилә елында бу – яшьләребез өчен киләчәккә зур һәм төпле нигез. Ил һәм республика районнары һәм шәһәрләре буйлап йөргәндә, без Президент әйткәнчә, балалар бакчалары һәм мәктәпләрнең ремонтка мохтаҗ булуын күрәбез. Алдагы 6–7 ел зур әһәмияткә ия булачак. Бу – яшьләр мәнфәгатьләренең дәүләтнең өстенлекле эш юнәлеше булуы билгесе.

ТАТАР ЭШМӘКӘРЕ – АВЫЛ ТОТКАСЫ

4–6 мартта Казанда XII Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре җыены уза. Кемнәр алар – бүгенге татар «бай»лары? Җыеннан соң нинди нәтиҗәләр ясала?

Әлеге һәм башка сорауларны без Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шура рәисенең беренче урынбасары – Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Данис ШАКИРОВка бирдек.

:: Данис Фәнисович, эшмәкәрләрнең милләт үсешенә кертәкән өлеше ни дәрәҗәдә зур дип саныйсыз?

– Авыл гомер-гомергә илнең, татарның яшәү чыганагы булып торды, ул бүген дә, иртәгә дә шулай булачак. Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре җыены да татар авылын яшәтү мәсьәләләренә багышлана. Шуңа күрә безгә эшмәкәрләр үзенең өлкәсендә, җирлегендә, авылында татар яшәешен тәэмин итүчеләр, авылны яшәтүчеләр буларак кадерле. Төбәкләрдәге татар авылларын торгызу, мәдәният йортларының, ФАПларның, социаль объектларның уңышлы эшләве – шушы эшмәкәрләр җилкәсендә. Татар конгрессы 2024 елны Шәхесләр елы дип игълан итте. Шул уңайдан мин татар авылларын торгызучыларны бүгенге көн шәхесләре дияр идем. Яшь буын авыл җирлегендә калсын өчен, беренчедән, аларны эш һәм яхшы хезмәт хакы белән тәэмин итәргә, икенчедән, яшәр өчен шартлар тудырырга кирәк. Шуңа күрә авылларны саклау механизмының төп юлы да – анда эшмәкәрлекне үстерү. Ул хәрәкәт бүген бар, чөнки авыл тормышы зур үзгәрешләр кичергән чорда халык арасыннан чыккан булдыклы кешеләр, базар мөнәсәбәтләреннән файдаланып, яңача эшли башладылар. Авылны яшәтүнең тагын бер алшарты ул – милли тормыш һәм дин. Гөрләп торган татар авылларында диннең көчле булуы шуны дәлилли. Шунысы куанычлы: соңгы елларда эшмәкәрлеккә яшьләр дә тартыла. Әйтик, Чувашиянең данлыклы Шыгырдан, Тукай, Урмай авылларындагы өч катлы йортларның беренче катында – әби-бабай, икенчесендә – әти-әни, өченчесендә бала-чага, яшьләр яши. Бу – бик күркәм күренеш бит. Һәм быел, Россиядә игълан ителгән Гаилә елында, без үз һөнәрләрен балаларына, оныкларына тапшырган гаиләләр турында күбрәк сөйләячәкбез, күрсәтәчәкбез. Ә андыйлар бездә бар.

:: «Татар байлары» дигән төшенчә бүген эшлиме?

– Халык телендә «Уң кул биргәнне сул кул белмәсен» дигән бик матур бер әйтем бар. Бүгенге көн эшмәкәрләре матди яктан ярдәм итүләрен сөйләп йөрми. Беренчедән, алар аны күңел кушуы буенча эшләсә, икенчедән, бүгенге шартларда үз исемеңне яңгыратмау отышлырак. Алар өчен эш нәтиҗәсе мөһимрәк. Ә андый эшмәкәрләр һәр төбәктә бар. Моннан тыш, эшмәкәрлекне Сабан туйларына өлеш кертүчеләр белән генә бәйләргә кирәкми. Алар – ел дәвамында туган авылында яшәп, шул авылны күтәрүчеләр.

:: Инде ничә ел уздырыла торган җыенның нәтиҗәләре нинди? Ул аралашу, фикер алышу, сөйләшүгә генә кайтып калмыймы?

tatarstan.ru

– Әгәр ул кирәксез чара булса, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның җыенны оештыруга хәер-фатихасы булмас иде. Аннан соң җыен меңләгән кешене дә бер мәйданга туплый алмас иде. Биредә катнашучыларның һәркайсы – эш кешесе, кырык якка чәчелеп яткан эшләрен калдырып киләләр икән, бу җыенның кирәклеген һәм мөһимлеген күрсәтә. Алар монда кунак булыр өчен җыелмый. Өч көн дәвамында барган эшлекле чараларда бик теләп катнашалар. Шушы кешеләрнең җыелуы табигый булып күренсә дә, әлеге хәрәкәтнең нигезендә бик четерекле мәсьәлә ята. Тагын шунысына басым ясап әйтәм: эре эшмәкәрләр «Татарстанның эшлекле хезмәттәшләре» форумына җыела. Ә монда урта һәм кече бизнес вәкилләре турында сүз алып барыла. Һәм безгә йөзләгән сыер асраучы фермерлар түгел, ә уртакул эшмәкәрләр кирәк.

:: Шулай да бу тәҗрибә уртаклашу кайсы якка күбрәк файда китерә? Без чит төбәкләрдәге эшмәкәрләргә нәрсә тәкъдим итә алабыз? Аларда безнекеләр өчен нинди шартлар бар?

– Беренчедән, монда инвестицияләр турында сүз алып бару дөрес түгел, ягъни җыенда теге яки бу төбәкләрдәге эшмәкәрләрнең Татарстанга керү мәсьәләсе тормый. Ул – башка форумның максаты. Безнең төп бурыч – тәҗрибә уртаклашу нәтиҗәсе буларак, үзләренең җирлекләрендә билгеле бер тәртип-кагыйдәләрне кертеп җибәрү. Без алардан татар мохитен булдыру, тормышын кору өчен ярдәм сорыйбыз, алар – үз җирлекләрендә аерым бер проектларны алга сөрүчеләр. Әйтик, Бөтенроссия татар авыллары ассоциациясе рәисе Фәнир Галимов Башкортстанның Туймазы районы Төмәнәк авылында «Бабай утары» этнокомплексын булдырды. Самара өлкәсенең Гали авылында барысы да диярлек үсемлекчелек белән шөгыльләнә, теплицалар тоталар. Форум делегатлары, аннан йөреп кайткач, шушы юнәлешкә игътибарын арттырды. Чувашия авылларын күреп кайткач, милли тормыш һәм динне бергә үреп баруның бер системасын булдырдылар. Без Казанга килгән эшмәкәрләргә Татарстандагы программалар турында түгел, ә федераль ярдәмне куллану шартлары турында сөйлибез. Ә бит күпчелек эшмәкәрләр дәүләт ярдәме турында белми. Һәм алар аңа өметләнми дә.

:: Төбәкләрдәге милли эшмәкәрлеккә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның мөнәсәбәте нинди?

– Татар эшмәкәре – кайсы гына төбәктә яшәсә дә, татар дөньясының таянычы, терәге. Шул ук вакытта аларның карашлары Казанга төбәлгән, безгә тартылалар: Татарстан теге яки бу юнәлештә нәрсә эшли, нәрсә тәкъдим итә, федераль программаларны ничек тормышка ашыра? Аларны күрсәтү, тәҗрибә уртаклашу – барысы да Татарстанның никадәр тарту көче барлыгын дәлилләүче фактор булып тора. Тәҗрибә уртаклашу белән беррәттән, алар, Татарстанга килеп, үз күзләре белән күрә, аннан соң үзләрендә сыный. Иң мөһиме: җыенда катнашучы һәр эшмәкәрнең үз милли йөзе бар. Бу яктан караганда, милли эшмәкәрлекнең роле зур.

:: Татарстанда да, башка төбәкләрдә дә татар эшмәкәрләре элек-электән терлекчелек белән игенчелеккә йөз тотып эшли. Соңгы елларда яңа юнәлешләр барлыкка киләме? Яңалыкка омтылу күзәтеләме?

– Терлекчелек һәм игенчелек белән беррәттән, теге яки бу продукцияне эшкәртү һәм сату мәсьәләсе дә бар. Бу уңайдан кооперация системасы эшли башлады. Моннан тыш, бакчачылык тармагы киң җәелеп килә. Бүген Россиядә җиләк-җимешкә ихтыяҗ бик зур. Шуңа күрә алма бакчалары үстерүгә игътибар артты. Күптән түгел генә без, татар атының генетикасын тикшертеп, татар токымын булдырдык. Чираттагы максатыбыз кышчылык тармагына юнәлтелгән һәм ул – казның татар токымын булдыру. Татар авылларында хәләл продукция җитештерү буенча шактый тәҗрибә тупланды. Хәләл ризык ул – яшәү рәвеше дә, продукциянең сыйфаты да.

:: Татар авыл эшмәкәрләренә хас нинди уртак авырлыклар бар?

– Татар эшмәкәрлегенә аяк чалучылар – эре агрохолдинглар. Пай җирләрен тапшыру, дәүләт субсидияләрен зур күләмдә аларга бирү эшмәкәрлекне дә кимәтә, татар авылының киләчәген дә шик астына куя. Ләкин мин – рухым белән позитив кеше. Һәм җыенга килгән эшмәкәрләр белән аралашудан туган фикер: татар авылларының киләчәге бар. Киләчәктә сыйфатлы азык-төлек мәсьәләсе алга калкып чыгачак һәм халык үз-үзен продукция белән тәэмин итәргә омтылачак. Ә продукция бары тик үз җиренә ия кешедә генә булачак һәм, телиме-теләмиме, ул барыбер җиргә кайтачак.

Зәһрә САДЫЙКОВА

XII БӨТЕНРОССИЯ ТАТАР АВЫЛЛАРЫ ЭШМӘКӘРЛӘРЕ ҖЫЕНЫНА КАГЫЛЫШЛЫ КЫЗЫКЛЫ ФАКТЛАР

✓ Казанга илебезнең **50**гә якын төбәгеннән **800** татар эшмәкәре җыела.
✓ Делегатлар җибәргән иң ерак төбәкләр – Красноярск өлкәсе һәм Бурятия.
✓ Иң зур делегация быел да Башкортстаннан килә.
✓ Эшмәкәрләр быел, аерым эш тәҗрибәсен уртаклашу өчен, Кукмара районына барачак.
✓ Җыенда **4** дискуссия мәйданчыгы эшләячәк: авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү һәм сату мәсьәләләре, авылларны саклау һәм үстерүдә татар брендының роле, игенчелек, үсемлекчелек тармагындагы инновацияләр һәм белгечләр әзерләү, терлекчелек. Авыл хуҗалыгына кадрлар әзерләү мәсьәләсе дә читтә калмаячак.
✓ Бүген Россиядә **4200** татар авылы бар. Татар дөньясында үзенең яшәеше белән Чувашиянең Тукай, Урмай, Шыгырдан авыллары, Самара өлкәсенең Гали авылы, Камышлы районы, Пенза өлкәсенең Урта Әләзән авылы, Пермь краеның Барда районы, Мари Элнең Бәрәңге районы, Мордовия Республикасының Аксюн, Азюрка авыллары аерылып тора.

МИЛЛИ КОД: ЭШМӘКӘРЛЕК

Халкыбызның милли кодлары – милли брендларыбыз бүген кемнәр кулында? Бөтендөнья татар эшмәкәрләренә ярдәм итү ассоциациясенең башкарма директоры Фәрит УРАЗАЕВ белән шул хакта сөйләштек.

Татар казы

Күркәм йолабыз буенча, каз һәрвакыт затлы ризык, табын күрке булып саналган. Бүген Россиядә каз үрчетү – татар гаиләләре кулында. Хәзерге вакытта 25ләп эшмәкәребез бар, алар карамагындагы ана казлар саны – 250 меңнән артык. Киләчәктә татар казы токымын булдыру, рәсми рәвештә теркәү фикере дә бар.

УҢЫШКА ИРЕШКӘН ЭШМӘКӘРЛӘР

● **Ирек Хәмәдишин (Мөслим районының Баек авылы).** 16 мең ана каз тота, яшь казлар саны ел саен 150 меңгә җитә. Татарстан районнары һәм күрше төбәкләр белән эшли.

● **Равил Лотфуллин (Чувашия)** 65 мең ана каз тота. Күрше төбәкләр һәм БДБ илләре белән эшли.

Татар аты

Безнең рәсми рәвештә теркәлгән татар токымлы атларыбыз бар. Гомумән, ат рухы – татарның аерылгысыз өлеше. Кызганыч, бүген «ат» дигәндә, халык күбрәк казылык, колбаса ясауны гына күз алдына китерә. Ләкин атка бәйле борынгы йолаларыбыз да бар бит әле. Шөкер, аларны халыкка кайтаручылар да бар. Гомумән, бүген бу юнәлештә 30лап эшмәкәр исәпләнә.

УҢЫШКА ИРЕШКӘН ЭШМӘКӘРЛӘР

● **Фәрит Нәбиуллин (Лениногорск районының Карабаш авылы).** Ат үрчетеп кенә калмый, борынгы йолаларны торгызу эше белән дә актив шөгыльләнә. Әйтик, «Аударыш», «Күк бүре» көрәшләрен оештыра.

● **Сәгыйтьҗан Идиятуллин (Башкортстан Республикасы).** Мең баштан артык атлары бар. Сәгыйтьҗан әфәнде гаиләсе белән әтисенең эшен дәвам иттерә.

Татар балы

Умартачылык белән татар халкы элек-электән шөгыльләнгән. Бу кәсеп милләтебезне бал корты сыман бик тырыш булырга өйрәтә. Бүген республикабызда 12 мең кеше умарта асрый, алар кулында 108 мең оя исәпләнә. Ә Башкортстанга чыксак, бу санны унга тапкырларга кирәк.

УҢЫШКА ИРЕШКӘН ЭШМӘКӘРЛӘР

● **Шәрәфетдиновлар гаиләсе (Чүпрәле районының Иске Шәйморза авылы).** Гаилә башлыгы Юлдаш әфәнде һәм аның улы нәсел эшен дәвам иттерә.

● **Раил Хисмәтуллин (Пермь крае).** Ул нигез салган компания инде өч дистә елдан артык бал продукциясенең 200ләп төрен җитештерә һәм 20ләп илгә сата.



Бакчачылык

Бүген авылларыбызны саклыйбыз һәм үстерәбез дисәк, без бер күренешкә игътибар итәргә тиеш. Татарстанда 4 млн гектардан артык җир бар, шуның 450 мең гектары – авыл эчендәге җирләр. Бу – дөньяда иң кыйммәтле җирләр, чиста органика. Кызганыч, бүген алар буш ята. Экологик чиста, хәләл продукт – шулай ук татарның милли коды.

УҢЫШКА ИРЕШКӘН ЭШМӘКӘРЛӘР

● **Альфред Хәйруллин (Чүпрәле).** 197 гектар җирдә – алма агачлары, 8әр гектар җирдә – кура һәм җир җиләге (виктория), 30 гектар җирдә кара карлыган үстерә һәм Татарстан районнарына, күрше төбәкләргә сата.

● **Җәмил Дәүләтшин (Буа).** Дәүләтшиннар гаиләсе 200 гектарда – алма агачлары, 15 гектарда – кура җиләге, 5 гектарда – җир җиләге (виктория) үстерә. Эшкәртүне дә (җиләк-җимеш продукцияләре җитештерү) башлап җибәргәннәр.

Тальян

Тальян гармунсыз татарны күз алдына китереп булмый. Ул бүген дә һәр татар авылында яши. Гармун ясау эшен яшәтүче – ТАССРның йөз еллыгына йөз тальян гармун эшләп биргән атаклы остабыз Айрат Харисов.

УҢЫШКА ИРЕШКӘН ЭШМӘКӘРЛӘР

● **Айрат Харисов (Казан).** 30 елдан артык гармун ясау белән шөгыльләнә. Ул ясаган гармуннар татарлар яшәгән төбәкләрдә генә түгел, чит илләрдә дә бар.

Шәл

Халкыбызны гасырлар буе җылыткан, илһамландырган хәзинәләребезнең берсе ул. «Шәл» диюгә, күз алдына милләтебез бизәкләре – ак әбиләребез килеп баса.

УҢЫШКА ИРЕШКӘН ЭШМӘКӘРЛӘР

● **Әпсәләмовлар гаиләсе (Оренбург).** Татар мамык шәле җитештерү эшен алар чирек гасыр элек үк башлап җибәргән. 180 кешене кул эше белән тәэмин итәләр. Мамык бирә торган ике мең баштан артык кәҗә асрыйлар.

Сәламәтлек

Сәламәт милләт, сәламәт токымның гына киләчәге бар. Бу хакта сөйләшкәндә, беренче чиратта, эчкән суыбыз турында әйтергә кирәк. Әйтик, чишмә фәлсәфәсе татар халкында аерым урынны алып тора. Шулай ук файдалы үләннәр, чәйләр дә – милли брендыбыз.

УҢЫШКА ИРЕШКӘН ПРОЕКТ

● **«Сәламәт милләт».** Әлеге проект кысасында фәнни-гамәли конференцияләр уза, чишмәләрнең шәҗәрәләре төзелә. Әйтик, соңгы берничә елда Саба һәм Мөслим районнарындагы 100дән артык чишмәнең шәҗәрәсе төзелгән.

Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде

Сәрия МИФТАХОВА

ТАЯНУ НОКТАСЫ

Башкортстан, Төмәнәк авылы

Рух

Татар ярлы булырга тиеш түгел. «Россиянең татар авыллары ассоциациясе» Бөтенроссия иҗтимагый оешмасы рәисе, эшмәкәр, җырлар авторы Фәнир Галимов шундый фикердә. Аның белән татар авылларының бүгенгесе, киләчәге, тел мәсьәләсе турында сөйләштек. Әлбәттә, авылында төзегән «Бабай утары» этнографик комплексы да читтә калмады.

Россиядә хәзерге вакытта 4 меңләп татар авылы бар. Моннан ун ел элек 4300 тирәсе булган. Авыллар картая. Кызганыч, берничә кеше генә яшәгәннәре дә бар. Фәнир Галимов фикеренчә, 2–3 өй калган, мәктәбе, бакчасы булмаган авыл – авыл түгел. Берничә әби-бабай белән генә аны саклап булмый. Шуңа күрә ул Туймазыда оештырган «Төмәнәк» татар үзәгенә дә, төрле чараларга да яшьләрне күбрәк җәлеп итү ягында.

– Россиядә татар авылларының хәле җиңел түгел. Шәһәр тирәсендәгеләрендә тормыш кайный әле. Авылларны саклау өчен – тел, телне саклау өчен авыл кирәк. Бу ике төшенчә бер-берсенә нык бәйләнгән, – ди Фәнир Галимов. – Авылда йортлар, социаль объектлар төзелә анысы. Әмма терлекләр саны кими бара, авыл халкы шәһәрчә яшәргә тырыша. Көтүдән сыерлар мөгрәп, урам тутырып кайтмаса, чыбыркы тавышы ишетелмәсә, таң атканда әтәчләр кычкырмаса, нинди авыл булсын инде? Ул шәһәр була. Аның бөтен яме шунда бит. Йортларга газ, ут кергән, бәдрәф өйдә... Күпләр хәзер урамга чыгып та карамый. Күрше күршегә йөрми, капкалар ябык. Боларга карап, йөрәк әрни.

«Россиянең татар авыллары ассоциациясе» бөтенроссия оешмасы җитәкчесен татар авылларында балаларның урамда русча сөйләшүе дә борчый. Бу урында ул үз оныкларын да мисалга китерде. «Минем белән татарча сөйләшәләр, урамга чыккач, рус теленә күчәләр. Дуслары шулай сөйләшкәч, үзе генә ала карга булып йөри алмый бит инде.

Авыллар шәһәргә әйләнеп бара», – ди Фәнир әфәнде.

Ул үз авылында җиде ел элек «Бабай утары» төзегән. Аның барлыкка килүе дә тел мәсьәләсенә бәйле.

– Мин оныкларыма бабалары турында сөйлим, ә алар аңламый. «Ничек инде утсыз, телефонсыз яшәгәннәр?» – дип аптырыйлар иде. Бала-чагага тотып карарга кирәк. Утарны төзегәндә, оныкларым да булышты, – ди эшмәкәр.

Этнографик комплекс туган авылы – 325 еллык тарихы булган Төмәнәкнең XVII гасырдан алып бүгенге көнгә кадәр тормышын үз эченә ала. Анда 4 йорт бар. Абзар-сарай, кара мунчалар белән. Һәр өй аерым бер гасырга багышланган. Утарга әби-бабайлар балаларын ияртеп килә. Аларга барысы да кызык. Туймазы һәм күрше Шаран районнарыннан килеп карамаган кеше калмаган. Сүз уңаеннан, «Бабай утары» узган ел Россия грантын откан.

Утарда дүрт ел рәттән «Сәләт» лагере оештырганнар. Җәен Россиянең төрле төбәкләреннән 350 бала ял итәргә килә. Фәнир абыйлары «Татарча сөйләшегез!» дигән таләп куйган. Кайберләре – катнаш гаиләдән. Алар өйләренә күпмедер дәрәҗәдә татар сүзләрен өйрәнеп кайтып китә. Кызлар, токмач кисеп, аш, бәлеш пешерә. Малайлар себерке бәйли, мунча яга, атлар янында кайнаша. Төрле уеннар җыеп, самавыр кайнатып чәй эчәләр. Менә ул милли мохит!

Төмәнәктә 500 йорт исәпләнә, 1250ләп кеше яши. Авыл елдан-ел үсә бара. Бакча, мәктәбе, клубы һәм башкасы бар. Туймазыдан нибары сигез чакрым гына ераклыкта урнашкан авыл халкы нефть, газ оешмаларында, заводларда эшли. Авылда мал тотучылар сирәк. Галимовлар үзләре исә ат асрый, кымыз ясап сату белән шөгыльләнә. Бахбайлар саны – 200ләп баш. Фәнир абыйның атлар асравы авылга ярдәм итәсе килүдән башланган. Банкротлыкка чыккан колхозны таркатмыйча, 17 ел шушы эш белән шөгыльләнә.

«Үзең турында сөйләү – бик авыр нәрсә ул. Моны эшләдем, тегене дип, мактанып утыру дөрес булмас», – дип, кыска тотты Фәнир әфәнде һәм сүз янә татарның уҗәтлеге, тырышлыгы юнәлешенә борылды.

– Татар һәрвакыт бер-берсеннән уздырып яшәргә тырыша. Мин түбәне кызылга буясам, икенче кеше аны тагын да җетерәк төскә буйый. Капканы зәңгәр итсәм, ул тагын да яктырак итә. Бу – яхшы гадәт. Күршедә әйбәт үрнәк бар икән, ник әле ул аңа тиңләшмәскә тиеш? Татар сәүдәгәрләре гомер буе бер-берсе белән ярышып эшләгән. Бу безнең каннан-канга күчеп килә, – ди Фәнир Галимов.

Пенза өлкәсе, Дәхтәрни авылы

Киләчәк



Мәктәп, бакча, спорт комплексы – бу аның авылга бүләге. Пенза өлкәсенең Кузнәй районындагы Дәхтәрни авылында яшәүче эшмәкәр Ренат Әбүзәров авыл халкы өчен игелек кылуын дәвам итә. Кеше күрсен дип түгел, Аллаһ ризалыгы өчен.

Дәхтәрни (Малый Труев) авылында 400ләп йорт бар. Барлыгы 1300ләп кеше яши. Мәктәпләре гасыр кичкән булган. Иске бинада сыйныфлар салкын. Кыш көннәрендә балалар хәтта дәресләрдә өс һәм аяк киемнәрен салмыйча утырган. Ренат Әбүзәров моңа битараф кала алмаган. Замана баласына шартлар тудырасы килгән аның. 2010 елда башлангыч мәктәп һәм бакча төзетеп, аны җиһазлап, дәхтәрнилеләргә яңа мөмкинлекләр ачкан. Хәзерге вакытта мәктәптә 34 бала укыса, бакчага 41 сабый йөри. Уку рус телендә оештырылса да, туган телләрен онытмыйлар. 1 нче сыйныфтан башлап татар теле дәресләре укытыла.

Авыл халкының сәламәтлеге дә мөһим Ренатка. Шуны уйлап, яңа мәктәп янында «Батыр» спорт комплексы да төзеткән. Анда тренажер, аэробика заллары, футбол кыры бар. Теләгән кеше йөри ала.

– Авыл халкы бик сөенде. Беренчедән, балалар өчен шартлар, икенчедән, укытучы, тәрбиячеләр һәм башкаларга эш урыны булдырылды, – ди хатыны Гөлнара. – Юл, ут, су... Иремнең туган авылы өчен башкарган эшләре аз түгел. Яңа скважина казытып, авылга су кертте. Торбалар искергән, суның сыйфаты начар иде. Хәзер чишмә суы кебек.

50 яшьлек эшкуарның күңелендә – күпме изгелек! Боларның барысын да авыл өчен дип башкара ул. Әби-бабайлары, әти-әниләре – шушы авылдан. Ренатның абыйлары да башкаларга ярдәм кулы сузарга атлыгып тора. Димәк, игелек орлыклары нәселдән килә. Бизнеслары – аграр, төзелеш юнәлеше буенча. Бу темага кагылмаска булдык. Ни өчен дигәндә, Ренат тыйнаклыкны ярата. Шуңа күрә дәшмичә калуны кулайрак күрде.

Хатыны Гөлнара – Ульян кызы. Аның белән дүрт бала тәрбиялиләр. Дини гаилә. Олы кызлары Казанда яши. «Эш урыннары булгач, яшьләр авылда төпләнеп кала. Ренат менә шуның өчен дә тырыша», – ди Гөлнара Әбүзәрова.

Мордовия, Аксюн авылы

Иман

Мордовия Республикасындагы Ләмбрә районының Аксюн авылы эшмәкәре Рәфыйк Фәтхуллов авылында мәчет төзеткән. Сабан туе дисеңме, башка чараларны оештыруы – авылдашларына, милләттәшләренә гел ярдәм итә ул. «Күбрәк биргән саен, бәрәкәте дә күбрәк», – ди эшмәкәр. Татарлар телен, динен югалтмасын, һәр яклап үссен өчен тырышуы.

Аксюн авылында 400ләп йортта 1500 тирәсе кеше яши. Дүрт урамлы авыл бу. Шуның өчесендә мәчет бар. Берсен Рәфыйк Фәтхуллов салдырган. Авылда – кибет, аннан читтәрәк кафе, кунакханә тоталар. Иллеләп кешегә эш урыны булдырган ул. Кем комбайнда, кем кафеда пешекче булып эшли. Арада машина йөртүче, сатучылар да бар.

– Халык дингә тартыла. Һәр урамның үз мәчете булса, йөрергә җайлырак бит. Менә шундый ният белән ике катлы иман йорты төзеттем. Халык намаз укырга йөри. Балалар да, хатын-кызлар да килә. Рамазанда авыз ачтырабыз. Шөкер, иман арта, – дип сөенә 59 яшьлек эшкуар.

Авыл Саранск шәһәреннән 8 чакрым ераклыкта. Яшәр өчен барлык мөмкинлекләр дә бар. Клуб эшли. Ике ел элек яңа мәктәп ачылган. Анда 120ләп бала укый. Булган әйберне саклап, аны үстерергә тырышалар. Рәфыйк әфәнде авылында баганаларга ут куйдырткан, зират, юлларны рәтләргә булышкан. Аксюн авылында оештырылган бөтенроссия авыл Сабан туе, республика Сабан туйлары да аның ярдәменнән башка узмый. Бүләкне дә юмарт өләшә. «Федераль Сабантуйларда икешәр машина әзерлибез. Берсе – көрәштә баш батыр калучыга, икенчесе – ат чабышында беренче урынны алучыга. Республика Сабан туенда да кыйммәтле бүләкләрне кызганмыйбыз», – дип шаккатырды ул.

«Авыл тавышлары» дигән ярыш та оештыра икән әле. Җыр-биюгә сәләте булган талантларны барлау өчен менә дигән мөмкинлек. Быел 16 нчы мәртәбә узачак.

Мондый игелекләр иясе кем ул, дисезме? Ул – «Юлдаш» крестьян-фермер хуҗалыгы рәисе. 24 ел элек оештырганнар аны. 2,5 мең гектар җире бар, 500 баш ат асрыйлар. Цехларында казылык, колбасаның 27 төрен җитештерәләр. Хәләл ризыкның тәмен Казан, Ульян һәм башка шәһәрләрдә яшәүчеләр дә белә.

– Мин – җир кешесе. Хезмәт белән сәүдәне бергә алып барабыз. Билгеле, авыл хуҗалыгы тармагында эшләү җиңел түгел. Ашлык бәяләре дә төште. Яңгыр яуса, һава торышы әйбәт булса ярый ла. Табигатьне алдан фаразлап булмый бит. Узган ел гектардан 35 центнер уңыш алдык. Солы уңышы 50 центнерга җитте. Шөкер итәбез, – ди эшкуар.

Ярдәм сорап килүчеләр шактый. Ул моны аңлап кабул итә. «Кешене сөендерү күңелле бит ул. Башкалардан кызганмасаң, Аллаһы Тәгалә үзеңә дә күбрәк бирә. Бар халык мул яшәсен. Шул вакытта милләтебез дә бай булачак. Һәрберебез тырышырга, үз гаиләләребезне тәрбияләргә, башкалар турында да уйларга тиеш», – ди ул.

Хатыны Зәйтүнә белән алар ике ул: Рушан һәм Дамирны үстергән. Уллары инде, авылда яңа йортлар төзеп, башка чыккан.

КАЛДЫКТАН – ХИМИЯСЕЗ АШЛАМА

«ЭКОТЕРРА-Т» ОРГАНИК АШЛАМАСЫ БЕРЕНЧЕ СЕЗОНДА УК ЯХШЫ НӘТИҖӘ КҮРСӘТӘЧӘК

«АГРИУМ» фәнни-җитештерү предприятиесе авыл хезмәтчәннәренә «ЭкоТерра-Т» маркалы сыйфатлы органик ашлама тәкъдим итә. Ашлама үзенең югары дәрәҗәдә нәтиҗәле булуын раслады да инде.

«ЭкоТерра-Т» маркалы органик ашлама микроэлементлар һәм микроорганизмнарга бай биологик актив гумустан гыйбарәт. Аны керткәндә, туфрак гумуска баетыла. Биредә сүз туфрактагы бик мөһим процесс – гумус катламы булдырылу һәм торгызылу турында бара. Туфрак аннан башка гына уңдырышлы була алмый. Җиргә эләккән микроорганизмнар, үсемлек тамырлары, хайван калдыклары һәм органик калдыклар барысы бергә аңа уңай йогынты ясый.

Туфрактагы микроорганизмнарның үсемлекләр өчен бик зур әһәмияткә ия булуын, кызганыч, күпләр белми. Белсә дә, тиешле игътибар бирми. Алар тамыр тирәсендә – ризосфера өлешендә аеруча күп булырга тиеш. Туфрактагы микроорганизмнар асылда аның гумус катламын даими булдыру өчен кирәк (гумус микроорганизмнарның сулган үсемлекләрне эшкәртүләре нәтиҗәсендә барлыкка килеп, туфракның уңдырышлылыгына зур йогынты ясый). Соңгы дистә ел дәвамында авыл хуҗалыгын актив төстә үстерү агрохимияне бик нык куллануга китерде. Ә бу туфрактагы микроорганизмнарга тискәре йогынты ясый. Нәтиҗәдә туфракның яңару процессына зур зыян килә, аның физик-химик үзенчәлекләре, гумус катламы бозыла. Җыеп кына әйткәндә, туфрак ярлылана һәм уңдырышлылыгы кими.

Авыл хезмәтчәннәре органик ашламаның нәтиҗәсен инде беренче сезонда ук сизәчәк. Аның уңай тәэсире, минераль ашламалар белән керткән очракта, 3–5 елга җитәчәк. «ЭкоТерра-Т» – Россия Агрохимикатлар һәм ашламалар реестрына кертелгән тере туфрак микроорганизмнарыннан торучы бердәнбер ашлама. Аннан файдалану, инде әйткәнебезчә, туфракның уңдырышлылыгын арттыру (елдан-ел артачак), химиясез мул уңыш үстерү мөмкинлеге бирә.

Шуңа күрә хәзер туфракның гумус катламын торгызу, PH составын яхшырту, органик ашлама кертү зарурлыгы килеп туды. «ЭкоТерра-Т» маркалы биогумус нәкъ менә шушы максатка ирешү мөмкинлеге бирә. Биогумус кертү туфракта микроорганизмнар һәм органик матдәләрне торгызу, туфракның PH составына уңай тәэсир итү, димәк, туфракның уңдырышлылыгын арттыру мөмкинлеге бирә.

«ЭкоТерра-Т» органик ашламасын җитештерүдә чимал булып кош тизәге тора. Анда фосфор, калий һәм азот, шулай ук башка файдалы микроэлементлар күп.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: «ЭкоТерра-Т» органик ашламасы лицензияле производство мәйданчыкларында, әйләнә-тирә мохитне саклау турында законны катгый төстә үтәү нигезендә җитештерелә. Җитештерү мәйданчыгында билгеле бер характеристикаларга ия булган чимал өемнәре булдырыла. Шуннан соң чималга тиешле нисбәттә биопрепарат кертелә. Әчү процессы тәмамланганнан соң, ни дәрәҗәдә әзер булуын, сыйфат күрсәткечләрен билгеләү өчен, ашламадан пробалар алына. Әзер булуына инангач, сынау беркетмәсе алынгач, «ЭкоТерра-Т» заказчылар белән төзелгән башлангыч килешүләр нигезендә тиешле урыннарга төяп озатыла. Ә инде туфракка ашлама тарату җиһазы ярдәмендә кертелә. Биогумус кертү нәтиҗәсендә туфракның гумус катламы торгызыла һәм уңдырышлылыгы арта. Шулай итеп, туфрак макро- һәм микроэлементларга баетыла, аның физик-химик сыйфатлары яхшыра. Шул ук вакытта, туфракта микроорганизмнарны торгызу, микробиологик процессларны яхшырту хисабына, агрохимиянең тискәре йогынтысы кими.

«АГРИУМ» фәнни-җитештерү предприятиесе кеше эшчәнлегенең әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын киметүне үзенең төп бурычы итеп саный. 100 процент органик ашлама җитештереп сату – төп эш юнәлешләренең берсе. Хәзерге вакытта оешма федераль округның үзәк өлеше һәм Шри-Ланка, Пакьстан, Әфганстан кебек чит илләр, Африка илләре предприятиеләре белән уңышлы хезмәттәшлек итә.
Калдыклар – теләсә кайсы производствоның аерылгысыз өлеше. Аларны дөрес итеп утильләштерүнең әйләнә-тирә мохитне саклау өчен чиктән тыш мөһим булуын аңлатып торасы да юк. Компания 2500 төрдән артыграк калдыкны утильләштерү һәм зарарсызландыруга кабул итә. Болар – авыл хуҗалыгы калдыклары, оргтехника һәм җиһазлар, куллану, җитештерү калдыклары һәм башка калдыклар.

+ 7 843 272-50-46
info@agrium.tech
www.agrium.tech
Проектлар группасы җитәкчесе Гаделшин Илгиз Исрафилович
+7 965 584-97-37

Реклама

4 март | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «Кызган казан» 6+
11.00 «Выборы-2024» 12+
11.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
12.00, 22.40 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00 «Семь дней» 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.00 «Халкым минем…» 12+
16.30 «Сөйләшергә вакыт» 16+
17.30 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Национальный калейдоскоп» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Заман көзгесе» 6+
22.10 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
23.30 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
00.25 «Каравай» 6+
00.50 «Фолиант в столетнем переплете» 16+
01.05 «Җырлыйк әле!» 12+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00, 00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.30 «Заман көзгесе» 6+
17.00, 19.10, 22.20, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
17.30, 00.40 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.35 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
21.55 «Кызган казан» 6+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «СОЮЗ СПАСЕНИЯ» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 «Александр Проханов. Исповедь» 18+
00.55 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.35, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
15.00 Выборы Президента России-2024. Дебаты
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «АННА МЕДИУМ» 16+
23.30 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.10 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «Наши» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.50 «Кто кого?» 12+
06.30 «Всё о главном» 12+
07.00, 10.10, 12.55, 14.45, 16.50 Новости
07.05, 19.00, 21.45, 00.45 Все на Матч!
10.15 «Лица страны» 12+
10.35 «Игры Будущего» 16+
11.25 Футбол. МИР РПЛ. Обзор тура 6+
13.00 «Есть тема!»
14.15 «География спорта» 12+
15.20 Специальный репортаж 12+
15.40 «Громко»
16.55 Футбол. МЕЛБЕТ-Первая Лига. «Химки» – «Тюмень»
19.20 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. 1/8 финала
22.40 Футбол. Чемпионат Италии
01.40 Теннис. Winter Moscow Open 2024. Финал 6+
04.00 Лёгкая атлетика. Чемпионат мира в закрытых помещениях 6+

НТВ

04.50 «ПАСЕЧНИК» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ГДР» 16+
22.00 «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. НОВЫЕ ГОРИЗОНТЫ» 12+
00.40 «ОДИН ПРОТИВ ВСЕХ» 16+
02.25 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30, 05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.30, 04.25 «Давай разведёмся!» 16+
08.30, 02.45 «Тест на отцовство» 16+
10.45, 23.15 «Понять. Простить» 16+
11.50, 00.25 «Порча» 16+
13.00, 01.25 «Знахарка» 16+
13.35, 01.55 «Верну любимого» 16+
14.10, 02.20 «Голоса ушедших душ» 16+
14.45 «Кризисный центр» 16+
19.00 «РАЗВЕДЁНКА С ПРИЦЕПОМ» 16+
05.15 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.15 «СМЕРШ. ЛЕГЕНДА ДЛЯ ПРЕДАТЕЛЯ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 16+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 00.50 «ЛЮБОВЬ ЗЕМНАЯ» 16+
13.25, 18.50 «Специальный репортаж» 16+
14.10, 03.45 «НЕ ПОКИДАЙ МЕНЯ» 16+
15.00 Военные новости 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Ищу своих» 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ОТ БУГА ДО ВИСЛЫ» 12+
02.25 «ВНИМАНИЕ! ВСЕМ ПОСТАМ…» 12+

5 март | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «МӘХӘББӘТ ХАКЫНА» 16+
11.00 «Выборы-2024» 12+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего…» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.30 «Заман көзгесе» 6+
18.00 «Казаннан – Казанга» 16+
19.00, 00.40 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Ватандашлар» 16+
23.00 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Если хочешь быть здоровым» 16+
01.05 «Башваткыч» 12+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Камит Җәвит» 16+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 18.20, 23.10, 04.20 «Җырлыйк әле!» 12+
09.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00, 19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
03.30 «Идрис Газиев тәкъдим итә» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
07.55 Выборы-2024
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 Проект «Цивилизации» 16+
21.00 «Время»
22.00 «СОЮЗ СПАСЕНИЯ» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 «Мой друг Жванецкий» 12+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.35, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
15.00 Выборы Президента России-2024. Дебаты
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «АННА МЕДИУМ» 16+
23.30 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.10 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.50 «Кто кого?» 12+
06.30 «География спорта» 12+
07.00, 10.10, 14.45, 16.40 Новости
07.05, 15.40, 21.45, 01.00 Все на Матч!
10.15, 15.20 Специальный репортаж 12+
10.35 Еврофутбол. Обзор 6+
11.45, 19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. 1/8 финала
14.15 Фрирайд. Мировой тур 6+
16.45 Футбол. МИР РПЛ. Обзор тура 6+
18.15 Смешанные единоборства. UFC. Жаирзиньо Розенстрайк против Шамиля Газиева 16+
22.40 Футбол. Лига чемпионов. 1/8 финала
04.00 Дзюдо. Турнир «Большого шлема» 12+

НТВ

04.55 «ПАСЕЧНИК» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ГДР» 16+
22.00 «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. СИМБИРСКИЕ МОРОЗЫ» 12+
00.50 «ОДИН ПРОТИВ ВСЕХ» 16+
02.35 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ

07.25, 04.30 «Давай разведёмся!» 16+
08.25, 02.50 «Тест на отцовство» 16+
10.40, 23.20 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.30 «Порча» 16+
12.55, 01.30 «Знахарка» 16+
13.30, 02.00 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.25 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Кризисный центр» 16+
19.00 «РАЗВЕДЁНКА С ПРИЦЕПОМ» 16+
05.20 «6 кадров» 16+
05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

07.00 «Сегодня утром» 16+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 00.55 «СУДЬБА» 16+
13.25, 03.15 «СТО ДНЕЙ СВОБОДЫ» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Улика из прошлого» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ОТ БУГА ДО ВИСЛЫ» 12+
02.35 «Автомобили в погонах» 16+

ТАТЭНЕРГОСБЫТ

АО «Татэнергосбыт» уведомляет, что в соответствии со Стандартами раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии, утвержденными постановлением Правительства РФ от 21.01.2004 N 24, на официальном сайте АО «Татэнергосбыт» tatenergosbyt.ru размещена информация о ценах и объемах электрической энергии каждого свободного договора купли-продажи электрической энергии, зарегистрированного гарантирующим поставщиком на оптовом рынке в отношении его зоны деятельности, а также величина корректировки составляющей предельного уровня нерегулируемых цен при учете свободного договора купли-продажи электрической энергии, определяемая коммерческим оператором оптового рынка в соответствии с договором о присоединении к торговой системе оптового рынка.



РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Валентина СЕМЕНОВА

КӘЛШӘ ҮСТЕРҮ СЕРЛӘРЕ

Помидор, татлы борыч, кыяр, баклажан кәлшәләрен ничек дөрес итеп үстерергә?

Россельхозцентрның Татарстандагы филиалы җитәкчесе урынбасары Гүзәл ХӨСӘЕНОВА бакчачылар өчен бик мөһим бу эшләрне аңлатты.

СУ СИБҮ. Орлыкларның тишелеп чыгуы өчен бүлмә температурасының +25 градустан ким булмавы кирәк. Ә инде тишелгәч, үсентеләргә һәр көн саен су бөркергә һәм, мөмкинлеккә карап, һава дымландыргычтан (увлажнитель) файдаланырга. Туфракның өске катламы кипшерүгә карап, су сибәргә. Әмма суны кәлшәнең тамырларына түгел, бәлки савытның кырыйларына юнәлтү әйбәт. Үсентеләр тишелгәч, беренче тапкыр аз гына юешләтәбез. Ә инде берәр атнадан соң, һәрбер үсентедә икешәр яки өчәр яфрак пәйда булгач, суга аз гына тукландыргыч матдә өстәп сибәбез.

ТУКЛАНДЫРУ. Үсентеләрне гадәттә тишелеп чыкканнан соң ун көн узгач тукландыра башлыйлар. Комплекслы яки гади ашламалар белән. Ашламаны сатып алганда, маркировкасына игътибар итәргә кирәк. Ник дигәндә, кечкенә һәм зур үсентеләр өчен төрле ашлама таләп ителә.

vk.com

Үсенте яфракларының төсе үзгәрү, таплар барлыкка килү ашламаны артык күп кертүне яки туфракка дым җитмәүне аңлата. Мондый очракта кәлшәне, тамырларын юып, яңа туфракка утыртып карарга кирәк. Ә инде үсентегә нинди матдә җитмәвен төсенә карап беләбез.

НИНДИ ТӨСТӘ? Күе яшел төстәге яфраклары һәм шәмәхәрәк төстәге нык сабаклары үсентенең әйбәт тукландырылуы турында сөйли. Помидорның аскы яфраклары саргаеп коелса, азотлы ашлама кертергә кирәк. Ә инде барлык яфракларының саргаюы азотның кирәгеннән артык булуын аңлата. Үсентенең шәмәхә төскә керүе исә фосфор җитмәүгә бәйле.

КҮЧЕРЕП УТЫРТУ. Помидор кәлшәсенә яктылык кирәк. Тишелеп чыкканнан соң беренче өч көндә аны тәүлек әйләнәсе, шуннан соң – тәүлегенә 13–15 сәгать чамасы яктыртып тору киңәш ителә. Үсентеләле савытларны даими рәвештә яктыга таба борып торырга. Ә инде 2–3 чын яфрагы чыккач, күчереп утыртырга. Озынрак үсеп китсә, тирәнгәрәк утыртырга. Сүз уңаеннан, торф сәдәфләрендәге кәлшәне күчереп утыртасы түгел. Күчереп утыртканнан соң үсентеләрне өч-дүрт көнгә җылырак урынга куясы. Шуннан соң салкынчарак урынга күчереп, даими су сибеп һәм туфрагын йомшартып торасы була.

Туфракка күчереп утыртырга ике атна кала, үсентеләрне чыныктыру таләп ителә. Моның өчен аларны +15 градуслы температурада тотарга кирәк.

ЯҢА СУЛЫШ. Кайбер очракларда кәлшәләрнең үсүдән туктавын күзәтергә туры килә. Аларга яңа сулыш өреп җибәрү өчен, сәбәбен ачыклап (суны артык күп сибү яки аз сибү, туфракның начар булуы, үсентенең чирләве), микробиоашлама (Азолен, Мизорин, Уни-Фос) һәм микроашлама («Здоровый урожай» гуматы) кертергә мөмкин.

Ә инде кәлшә артык үсеп китсә, туфракка утыртканчы, үсешен тоткарлау таләп ителә. Моның өчен аны кабат күчереп утыртудан да яхшысы юк.

Гади генә шушы киңәшләрне тотканда, үсентеләр нык һәм сәламәт булып үсәчәк.

Исеңдә тот!

ҖЫЕРЧЫКТАН – ЖЕЛАТИН

Матурлык салонында бит тиресен «тарттыру» өчен беренче чиратта желатин кулланыла. Ә бит бу могҗизаны өйдә дә ясап була. Вакыт та, акча да янга кала!

▶ Салынып торган бит тиресен «тарттыру» өчен. Чиста савытка 4 аш кашыгы җылы су салып, 2шәр аш кашыгы желатин, глицерин һәм 2 чәй кашыгы бал өстибез. Кыска дулкынлы мичкә куеп, 1–2 минут тотабыз. Шуннан 4 аш кашыгы су өстәп болгатабыз да пыяла савытка бушатабыз. Катнашманы парланган чиста биткә һәм муенга сөртеп, 15 минут тотабыз. Аннары җылы су белән юып төшерәбез. Катнашма берничә тапкыр битлек ясарга җитә. Аны суыткычта сакларга мөмкин.

▶ Бит тиресен яшәртү өчен. Савытка 3 аш кашыгы кайнар су салып, 1 аш кашыгы желатин өстибез. 20 минутка бүртерергә куябыз. 2 аш кашыгы банан пюресы өстәп болгатабыз. Катнашманы биткә һәм муенга сылап, 20 минут тотабыз. Шуннан соң җылы су белән юып төшерәбез.

Тәмле булсын!

Арыш икмәгендә – итле кәбестә

Илсөя ШӘЙХЕТДИНОВА рецепты

Кирәк: *500 г тавык яки сыер ите (сөяксез өлеше), 200 г ысланган колбаса, 2шәр кишер һәм башлы суган, 3–4 кара җимеш, 1 стакан ак шәраб (су булса да ярый), 800 г кәбестә, 2 аш кашыгы кетчуп, 1 розмарин ботагы, төеләгән борыч катнашмасы, тәменчә тоз, 1 түгәрәк арыш икмәге, кыздыру өчен үсемлек мае.*

Тавык итен уртача зурлыктагы кисәкләргә турыйбыз. Калын төпле табага үсемлек мае салып, итне алтынсу төскә кергәнче, җиңелчә генә кыздырабыз. Суганны шакмаклап турап, ит янына салабыз да икесен бергә кыздырып алабыз. Угыч аша чыгарып, кишер өстибез. Тоз сибеп, тагын бераз кыздырабыз. Суда тотып йомшартылган каражимеш һәм колбаса өстибез. Тагын 3–4 минут кыздырабыз. Кәбестәне озынча итеп турап, табага салабыз. Шәраб (су) агызабыз. Кәбестә пешеп җиткәнче, салмак кына утта тотабыз. Тоз, борыч катнашмасы, розмарин һәм кетчуп өстәп, барысын бергә болгатабыз. 2–3 минуттан соң уттан алабыз.

Икмәкнең өстен капкач кебек кисәбез дә йомшагын алабыз. Итле кәбестәне шул «савыт»ка тутырабыз. Икмәкне кисеп, бәлеш кебек ашыйбыз.

Укучы хаты

ШПРИЦ КУЛЛАНАМ

Чәчкәнче, орлыкларны җебетү өчен шприцтан файдаланам. Бик уңайлы. Орлыклар эрерәк икән, энәсен алмыйм. Пешкәген салдырып, орлыкны шприцка тутырам да шуңа зарарсызландыргыч эремә (әйтик, марганцовка эремәсе) җыям. Берникадәр вакытка калдырам. Җебеткәннән соң орлыкны юарга кирәк булса, чиста су тутырып-бушатып, шприцта ук юам.

Раиса ВАСИЛЬЕВА. Казан

Кирәге чыгар

Тоз чамасы

Ризык тозсызрак булса, тоз өстәргә мөмкин әле. Ә менә артык тозлысын... Аш-су әзерләгәндә тозны күпме салу өчен, берничә кагыйдәне белеп тору беркемгә дә зыян итмәс.

✓ Балык кәтлите яки фрикаделька әзерләгәндә, 1 кило филега 20 г (2 чәй кашыгы) тоз кирәк. Ит кәтлите әзерләү өчен дә 1 кило фаршка шуның кадәр үк тоз саласы.

✓ Пирог камыры басканда 1 кило онга 12 г тоз (1 чәй кашыгыннан аз гына күбрәк) таләп ителә. Ә коймак һәм белен өчен – 15 г.

✓ Таралып торган карабодай боткасы пешерү өчен 1 кило ярмага 20 г тоз салсаң әйбәт. Сыеграк дөге боткасына – 1 кило ярма өчен 40 г тоз.

✓ Итле шулпага тозны әзер булырга 20–30 минут кала өстиләр. Ә балыкныкына – шулпаны куеп җибәргәндә үк.

✓ Бәрәңгене пешергәндә – башта ук, кыздырганда – әзер булгач кына тозлыйлар.

УРАЗАДА ЙОКЫ ДА – ГЫЙБАДӘТ

Мөселманнар өчен иң бәрәкәтле һәм хәерле рамазан аена аяк басабыз. 11 март – уразаның беренче көне. Бу изге айда мөселман кеше нәрсәләрне истә тотарга тиеш? Уразаны нәрсә боза? Кемнәргә ураза тотмаска ярый?

Бу һәм башка сорауларга «Әл-Мәрҗани Җәмигъ» мәчете имамы Ансар хәзрәт МИФТАХОВ җавап бирде.

:: Ураза ниятен татарча әйтергә ярыймы?

– Уразаны Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен тотабыз. Иң мөһиме – безнең ният. Ураза ниятен нинди телдә әйтсәк тә була. Гарәп телен белгәннәр гарәпчә әйтсен.

:: Кемнәргә ураза тотмаска да мөмкин?

– Мондый кешеләр төркеме дә бар. Әйтик, авыру кешегә (ураза сәламәтлегенә зыян китерсә, даими дарулар, уколлар кирәксә), ерак сәфәрдә булган, картлык зәгыйфьлегенә ирешкән, тоткында булган, йөкле, хәезле, бала имезгән хатыннарга, ач тору яисә сусауга түзәрлек булмаганда ураза тотмаска ярый. Кешене көчләп ураза тотарга мәҗбүр итсәләр дә, ураза тотмаска мөмкин.

Әмма авыру кеше, савыкканнан соң, уразага керергә тиеш. Ерак сәфәрдәге кеше дә, сәфәреннән кайткач, казасын кылсын. Бала үстергән ана да, баласы үскәч, казаларын үтәргә тиеш.

:: Ураза тоткан көн тизрәк узсын өчен, телевизор карау, музыка тыңлау, йоклау, интернетта утыру рөхсәт ителәме?

– Рамазан – елга бер генә килә торган ай. Бу айда әҗер-саваплар алырга ашыгырга, игелек кылырга кирәк.

Телевизор карау дигәндә, нindидер кирәкмәгән тапшырулар түгел, дини эчтәлектәгеләрен карасак, начарлыгы юк. Ләкин бу очракта да көн буе телевизорга текәлеп утыру кирәкми.

Йокы дигәндә, аз гына йоклап алу рөхсәт ителә. Әмма көнне йоклап уздыру килешми.

Интернет дигәндә, кирәкле нәрсәләр карап алу өчен куллансак була. Күңел ачу, вакытны заяга уздыру өчен түгел.

Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.): «Ураза тоткан кешенең йокысы – гыйбадәт, эндәшмәве – тәсбих, гамәле даими, догасы кабул ителгән, ә гөнаһысы гафу ителгән булыр», – ди.

:: Рамазан ае башлангач, аның башында өч көн, уртасында өч көн һәм ахырда өч көн тотсаң, тулы бер ай ураза тоткан кебек була, диләр. Бу дөресме?

– Башында ун, уртасында ун, ахырда ун көн тотсак, ураза кабул булыр. Рамазан ае адәм баласына тулы бер ай булып бирелгән. 12 айның берсе бу! 11 аен иркенләп, ашап-эчеп йөрибез бит. Бер ай уразалы булуыбыз организмыбыз өчен дә әйбәт булыр. Бу айны кыскартырга тырышырга кирәкми.

:: Намаз укымаган килеш тә ураза тотарга ярыймы?

– Адәм баласының биш бурычы бар: иман кәлимәсен әйтү, биш вакыт намаз уку, рамазан аенда ураза тоту, зәкят бирү, хаҗ кылу. Адәм баласы бу гыйбадәтләрнең берсен эшләми торып, икенчесен башкарса да, зыяны юк. Ләкин инде мөселман аларның барысын да үтәргә тырышырга тиеш. Һәр гамәлебез өчен җавап тотачакбыз. Хаҗга бармаган, намаз укымаган кешегә дә ураза тотарга мөмкин. Мөмкин генә түгел, ә кирәк тә! Уразаны бүген тота икән, киләчәктә намазына да басар, башка гыйбадәтләрне дә үтәр.

:: Сәхәргә тормыйча, кичтән ниятләп ятарга ярыймы?

– Сәхәр ашау – сөннәт гамәл. Пәйгамбәребез (с.г.в.) хәдисендә болай ди: «Сәхәрдә ашагыз, шул рәвешле үзегезне ураза тотар өчен ныгытыгыз». Сәхәр ризыгының шифасы да бар. «Таң атканчы ашагыз, монда бәрәкәт бар», – диелә хәдистә. Сәхәрне торып ашасак, хәерле булыр. Кичтән ниятләп ятсак, сәхәргә тора алмасак, әйләгә кадәр ниятләсәк тә ярый. Аллаһы Тәгаләдән сорыйк, Ул – уразаларыбызны кабул итүче. Коръән аша Аллаһы Тәгалә: «Таңда ак җеп белән кара җепне бер-берсеннән аерганчы ашагыз, эчегез, аннан соң кояш батканчы ураза тотыгыз», – дип әйтә.

:: Ифтарга берничә сәгать кала күрем килсә, ураза бозылган булып саналамы?

– Әйе. Әмма кеше уразасын тотып бетерсә дә ярый, шундук ашый башласа да рөхсәт. Күрем көннәрен санап, калган уразаны каза кылырга кирәк булачак.

УРАЗА ТОТАРГА НИЯТ КЫЛГАНДА УКЫЛА (СӘХӘР)

«Нәвәйтүән әсумә саумә шәһри Рамадаанә минәлфәҗри иләл-мәгъриби хаалисән лилләһи тәгалә».

Тәрҗемәсе: «Аллаһы Тәгалә өчен чын күңелдән ният кылдым ошбу көннең фарыз уразасын тотарга, таң атканнан алып кояш баеганчыга кадәр».

АВЫЗ АЧКАНДА УКЫЛА (ИФТАР)

«Бисмилләһир-рахмәәнир-рахиим. Аллаһүммә ләкә сумтү, үә бикә әәмәнтү үә гәләйкә тәүәккәлтү үә гәлә ризкыйкә әфтартү, фәгъфир лии йәә Гаффәәрү мәә каддәмтү үә мәә әххартү. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин. Әмин».

Тәрҗемәсе: «Әй, Аллаһым! Ошбу уразамны синең өчен генә тоттым вә Сиңа гына иман китердем, вә Сиңа тәвәккәл кылдым, вә синең ризыгың белән авыз ачамын. Әй, гөнаһларны ярлыкаучы Раббым! Минем моңа кадәр кылган гөнаһларымны да, соңгыларын да ярлыкасаң иде. Әмин».

ru.freepik.com

Белеп тор!

УРАЗАНЫ БОЗА	УРАЗАНЫ БОЗМЫЙ, ӘММА МӘКРУҺ (ШЕЛТӘЛЕ) САНАЛА	УРАЗА ВАКЫТЫНДА ТЫЕЛМЫЙ
• Борчак кадәр генә булса да ризык, теш пастасы йоту • Бер тамчы кадәр генә булса да су, дару йоту • Авыз тутырып косу • Җенси якынлык кылу	• Ризык һәм сагыз чәйнәү • Әдәпсез сүзләр сөйләү, гайбәт • Берәр азыкны, йотмыйча, телне тидереп карау • Иреннән үбү • Сатып алыначак малны (ризыкны) татып карау • Интектерә торган эш • Авызга тулган төкерекне йотып җибәрү • Авыруың көчәюен белә торып уразада булу	• Балага ризык чәйнәп бирү (баланың ризыкны башкача кабул итү мөмкинлеге булмаса) • Тәһарат вакытында мисвак белән тешләрне пакьләү • Госел коену

:: Ураза аенда социаль челтәрләрдә ифтар ашаганда төшкән фотоларын куялар, үзләренең уразалы булулары турында язалар. Болай эшләү рөхсәтме?

– Нинди генә гыйбадәт булса да, ул гамәл яшерен эшләнсә яхшырак. Изгелек кылабыз икән, ул рия гамәл булмасын өчен, күрсәтмәсәк хәерлерәк. Күрсәткән очракта да, дөрес итеп күрсәтергә кирәк. Ягъни «мин уразалы», «мин ураза тотам» дип түгел, «ифтарлар оештырыйк, Аллаһы Тәгалә савабын бирер» дип күрсәтергә була. Мактанып йөрү уразаның савабын киметеп, көне буе тоткан уразабызның ач торуга гына кайтып калуы ихтимал. Ураза тотканда телне дә, күзне дә, кул-аякны да яманлыктан сакларга кирәк.

:: Су белән хөрмәне ифтар догасына кадәр кабып куяргамы, әллә дога укыганнан соңмы?

– Ахшамга азан әйтелгәннән соң, хөрмә беләнме, су беләнме, тоз беләнме ифтар кылу тиешле. Аннан соң инде догасын укыйсы. Аннан соң, намазлы кеше намазын кыла, намазда булмаганы, рәхим итеп, ризыклана.

Сәхәрдән соң, эчендә ризык калмаслык итеп, авызны чистартырга, тешләрне пакьләндерергә кирәк. Аннан соң ниятлибез.

:: Тәравих намазына йөрү мәҗбүриме?

– Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Рамазан аенда тулы ышаныч белән һәм Аллаһтан савабын көтеп намаз кылган затның үткәндәге гөнаһлары кичерелер», – ди. Тәравих намазы – сөннәт гамәл. Кемнең телəге бар, бу намазны өйдә дә башкара ала. Мәчеттә дә укырга була. Бу – саваплы эш.

:: Ураза тотмаган килеш, ифтар мәҗлесләренә йөрергә ярыймы?

– Ифтар мәҗлесендә ураза тотмаган килеш тә катнашырга мөмкин. Ураза тотмаган кешеләр, бәлки, шул ифтарларда катнашып, вәгазьләр тыңлап, киләчәктә ураза тота башлар.

:: Ифтарга чакырдылар, әмма барасы килми. Нишләргә?

– Чакырган җиргә барырга кирәк. Ифтар, Коръән мәҗлесенә бигрәк тә. Барасы килмәсә, сәбәпләрен аңлатырга, дәшкән кешегә хәбәр итәргә кирәк. Чакырган җиргә бер дә нигезсез сәбәп белән бармый калу ярамый. Бу – килешми торган гамәл. Туганнар чакырса, бару икеләтә хәерле. Уразалы килеш ифтар мәҗлесендә катнашсак, савап булыр. Рамазан аен заяга уздырырга ярамый.

:: Уразалы килеш иннек сөртергә, хушбуй сибәргә, маникюр ясатырга ярыймы?

– Сөрткән иннекләр «питательный» булырга тиеш түгел. Ягъни алар төкерек беләнме, иреннәрне ялагандамы авызга, тамакка эләгергә тиеш түгел. Шуннан саклансагыз, рөхсәт ителә.

Маникюр мәсьәләсенә килгәндә, кеше намазлы икән, маникюр тәһарәт һәм госелнең дөрес итеп алынмавына китерә. Гыйбадәт кылганда, маникюрдан ераграк торсак иде. Хушбуй сибү рөхсәт ителә.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

ӘЛЕГЕ БИТТӘ КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ, ДОГАЛАР БУЛУ СӘБӘПЛЕ, КАДЕРСЕЗЛӘМӘВЕГЕЗ СОРАЛА

ӘЗЕРЛӘНЕП КЕР

Изге рамазан ае башланырга да санаулы гына көннәр калды. Ураза тотканда күңелебез генә түгел, тәнебез дә чистара. Бу айда сәламәтлеккә зыян килмәсен өчен, нинди кагыйдәләрне истә тотарга кирәк? Нинди чирләр вакытында ураза тотарга киңәш ителми? Тәҗрибәле табиблар белән шул хакта сөйләштек.

Ураза тоту кагыйдәләре

КФУ Университет клиникасының беренче категорияле табиб-гастроэнтерологы Айрат ЗЫЯТДИНОВ белән шул хакта сөйләштек.

:: Ураза тотканда кеше рухи яктан гына түгел, физик яктан да чистарына. Аңа ничек әзерләнергә?

– Кеше ешрак ашаган саен, аның ризыгы озаграк эшкәртелә, ул тиешенчә үзләштерелми. Нәтиҗәдә организмга файдалы матдәләр дә азрак керә. Шуңа күрә еш ашау кешенең организмына зыян китерә. Сирәк ашаганда организм үзенә эләккән файдалы матдәләрне, шул ук аксым, май, витаминнарны яхшырак үзләштерә, организмда токсиннар да азрак була. Кеше, гомумән, ашказанының мөмкинлекләрен белеп бетерми. Ашказанына ризык эләккәч, анда тоз кислотасы бүленеп чыга. Ул ризык эшкәртү өчен җаваплы. Ашказанындагы лайла исә аның эшчәнлеген көйләп тора. Кеше еш ашый икән, аның ашказаны билгеле бер вакытта тоз кислотасы бүленеп чыгуга яләшкән була. Шуңа күрә ураза тотарга уйлаган кеше аңа алдан әзерләнергә, акрынлап ашауны киметергә тиеш. Көндәлек тормышта да үзеңне сирәк ашауга ияләндерү хәерле. Юкса кеше ураза тотканда сирәк ашауга ияләшә дә, ураза тотмый башлагач, кисәк кенә элеккечә күп ашауга күчә. Шул сәбәпле, рамазан ае тәмамлангач, безгә ярдәм сорап килүчеләр арта.

:: Кемнәргә бөтенләй ураза тотарга киңәш ителми?

– Фәлән чирләр вакытында ураза тотарга ярамый, дип өздереп кенә әйтеп булмый. Аның махсус исемлеге дә юк. Һәр очрак индивидуаль. Нинди генә чир булмасын, ураза тотар алдыннан иң элек табиб белән киңәшләшү тиеш. Даими рәвештә дару эчеп торуны таләп иткән чирләрнең тынып торган вакытында (ремиссия) ураза тоту-тотмауны да табиб белән киңәшләшеп кенә хәл итәргә кирәк. Хроник чирләр баш калкыткан чорда ураза тотарга ярамый. Бу очракта иң мөһиме шул: чиреңне белә торып, хәлең, саулыгың булмаган килеш үзеңне мәҗбүриләп ураза тотып, чирнең тагын да азуына китердең икән, син, бердән, үзеңә зыян китерәсең. Ә бу – үзе үк зур гөнаһ. Икенчедән, син үзеңнең якыннарыңның күңелендә динебезгә карата начар мөнәсәбәт тудырырга мөмкинсең. Динебезне катлауландырырга кирәкми.

:: Ураза тотканнан соң хәлем, иммунитетым яхшырды, диючеләр дә очрый...

– Организмның нык, сәламәт булуы бавырның токсиннар белән тыгылмаган булуына бәйле. Ул чиста булса, кеше авыруларга да бирешми. Сирәк ашау аркасында организмның көче дә күбәя. Уразадан соң иммунит яхшыру шуның белән аңлатыла.

Айрат Зыятдиновтан ураза тотучыларга киңәшләр

1 Ураза вакытында иң мөһиме – иртәнге аш – сәхәр. Сәхәрдә бавырдан үтне чыгара торган ризыклар булырга тиеш. Бавырда үт җыелса, токсиннар барлыкка килә. Әгәр сәхәрдә берәр җиләк-җимеш, су белән җиңелчә генә капкалап алсагыз, үт бүленеп чыкмаячак. Шуңа күрә сәхәрдә терлек мае, терлек аксымнарына бай ризыклар ашарга кирәк. Эремчек, каймак, йомырка, атланмай, шулпа ашау хәерле. Майдан куркырга кирәкми. Акыл хезмәте белән генә шөгыльләнгән кешегә дә көненә ким дигәндә 100–110 грамм май кирәргә тиеш. Шушы ризыклар хисабына бавыр токсиннардан чистара, яхшырак эшли башлый. Ураза тотканда хәлсезлек, укшу, баш авырту да сирәгрәк күзәтелә.

2 Ифтар судан башланырга тиеш. Җылы су ашказанында көне буена җыелган лайланы юып төшерә. Шуннан соң гына төп ризыкка күчәсез. Әгәр җиләк-җимеш ашыйсы килсә, аны да су эчкәч, ашар алдыннан кабып куярга кирәк. Әгәр җиләк-җимешне ашаганнан соң капсаң, ул ашказанындагы ризыкны әчетәчәк.

3 Ифтар белән сәхәр арасында ким дигәндә биш сәгать вакыт узарга тиеш. Ник дигәндә, ризык өстенә ризык төшсә, ул ашказанындагы ризыкны эшкәртергә комачаулый, нәтиҗәдә ул чери. Шуңа күрә ифтар белән сәхәр арасында ризык капкалап йөрергә киңәш ителми. Ә менә җылымса су эчеп тору файдага гына.

4 Ашказанына кергән ризык 5–6, хәтта 7–8 сәгать ятарга мөмкин. Ашаганнан соң 1,5 сәгать су эчәргә ярамый. Ник дигәндә, ашаганнан соң су яки чәй эчсәк, тоз кислотасы начар эшли башлый. Әмма ашар алдыннан су эчеп куярга кирәк. Бу ашказанындагы лайланы юып төшерү өчен кирәк. Юкса, ризык турыдан-туры шунда эләксә, ашказанында ризык тиешенчә эшкәртелеп бетмәячәк. Организмга кергән микроб, вируслар да юк ителмичә, шул килеш калачак. Ашаганнан соң бик нык эчәсе килсә, бер-ике йотым яхшы чәй яки кәһвә эчеп куярга ярый.

Ни өчен баш авырта?

Илфак ЯРМИЕВ, РКБ табиб-неврологы:

– Кеше еш кына уразага әзерлексез керә. Шул сәбәпле уразаның беренче көннәрендә күпләр баш авыртудан зарлана. Аннары ураза тотканда организмда су кими. Бу исә, үз чиратында, мускулларның кысылуына китерә. Шуңа күрә ураза тотканда баш авыртса, хәлеңне бераз җиңеләйтү өчен, башны җиңелчә генә массажларга кирәк. Болай эшләгәндә мускуллардагы спазмнар язылып, авырту басылачак. Күпләр уразада организмнан токсиннар чыкканга баш авырта дип саный. Әмма алар бер-ике көндә генә чыга алмый.

Уразаның беренче көннәрендә кан басымы уйнаудан тилмерүчеләр дә очрый. Организм шул рәвешле яңа шартларга ияләшә башлый. Шуңа күрә бу чор җиңелрәк узсын өчен, ураза тотар алдыннан ашауны киметеп, суны күбрәк эчә башларга кирәк. Бүген авыруы булмаган кеше сирәк. Шуңа күрә ураза тотар алдыннан иң элек табиб белән киңәшләшергә кирәк. Яшәү өчен мөһим дарулар белән генә яшәгән (инсульт, инфаркттан соң, яман шеш һ.б.), инсулинга бәйле кешеләргә, инфекцияле авыру йоктырып, температура белән яткан, яңа гына операция кичергән, берәр әгъзасын сындырган, хроник чире баш калкыткан кешегә ураза тотарга ярамый.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Белеп тор!

Ураза тотканда нәрсә ярый?

✓ Кан алдыру, анализлар өчен яки донор сыйфатында кан тапшыру.
✓ Кан яки дару йотмыйча, тешне дәвалау һәм сыерып алу.
✓ Венага, тире астына яки мускулларга укол кадау.
✓ Дезинфекция яки ачык җәрәхәтне төзәтү максатларында дару мае (мазь), йод, яшел су (зеленка) куллану.
✓ Сөлек салдыру, хиҗама ясату.
✓ Әгәр тәме, тәэсире тамакка барып җитмәсә, борынга дару салу.

Нәрсә ярамый?

✓ Дару эчү, клизма, ингаляция ясау.

Дару, витаминны кайчан эчәргә?

Элина БОРҺАНОВА, табиб-терапевт, нутрициолог:

– Табиб иртәнге аштан соң дип язып биргән даруларны – сәхәрдән соң, кичке аштан соң эчәселәрен ифтарда эчәргә. Җитди дарулар турында сүз барганда, табиб белән киңәшләшергә кирәк. Көненә өч тапкыр дару эчәргә кирәк икән, уразаны калдырып тору хәерлерәк. Витаминнарны сәхәр белән ифтарда эчәргә мөмкин. Мин, гомумән, витаминнарны ризык белән алу яклы. Идеаль тәлинкә принцибы белән тукланган вакытта без көн дәвамында организм өчен кирәкле барлык файдалы матдәләрне алабыз. Мәсәлән, магний, В төркемендәге витаминнар организмга ярмалар, ипи белән керә. Яшелчә, үләннәр фолий кислотасы, С витаминына бай. Сары, кызыл яшелчә, җиләк-җимешләрдә А витамины бар. Майлар белән Е витаминын алабыз. Чикләвекләр – файдалы майлар, цинк, селен, бакыр чыганагы. Эремчек белән көнҗеттә – кальций, хөрмәдә калий күп. D витаминын ризык аша алып булмый. Аны өстәмә рәвештә эчәргә туры килә. Профилактика өчен аны көн саен 800–1000 МЕ (халыкара берәмлек) кулланырга кирәк. Әлеге витамин иртәнге якта эчелә. Чөнки ул йокыны качыра.

Идеаль тәлинкә:

¼ – аксымлы ризыклар (йомырка, эремчек, ит)
¼ – углеводлы ризыклар (ботка, токмач, кара ипи)
¼ – яшелчә, җиләк-җимеш
¼ – бер аш кашыгы май, чикләвек

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Бер сүз җитә

Уйламый әйтелгәне дә, әйтелми калганы да куркыныч. Сүзнең көче дә, тәэсире дә зур – моны һәркем белә, әмма кайчак тиешенчә бәяләми. Сәхифәбездәге әлеге сорау – җавап та тормыштагы әһәмиятле сүзләргә багышлана. Бу юлы без Татарстанның атказанган артисты Рифат ЗАРИПОВ белән сөйләштек.

:: Иң кадерле сүз?
– Әти-әнинең, телефоннан шалтыратып: «Исәнме, улым! Ни хәлләрең бар?» – дип әйтүе.

:: Бирешкәндә тартып торгызган сүз?
– Бисмилла.

:: Бик каты яралаган, рәнҗеткән сүз?
– Андый сүзләр юк.

:: Әйтәсе килеп тә, әйтә алмый калган сүз?
– Кайчак яраткан, якын кешеләребезгә әйтәсе килеп тә, кыенсыныпмы шунда, әйтми калган сүзләр. Кайвакыт: «Әти, әни, мин сезне шундый яратам!» – дип әйтү дә онытыла бит...

:: Бүген, хәзер ишетәсе килгән сүз?
– Ихлас сүзләр. Ярарга тырышып, икейөзләнәнеп әйтелгән түгел, чын күңелдән чыккан сүзләр җитми.

Аннан-моннан

Узып баручы атна ниләр белән истә калачак? Бу сорауга җавап итеп, социаль челтәрләрдәге «кайнар» яңалыкларны тупладык.

Татар кызы – «Мисс Европа – 2024». Азнакайда туып-үскән татар кызы Роза Гадиева Ливанның Бәйрут шәһәрендә узган «Мисс Европа – 2024» бәйгесендә җиңде. Татар кызы, 1,3 млн сумлык Сөмбикә-ханбикә костюмы белән сәхнәгә чыгып, бар кешене таң калдырды. Сүз уңаеннан, әлеге матурлык бәйгесендә Россия кызларының 2018 елдан бирле җиңгәне юк иде.

Марат белән Нгамбоның кызлары туган! Узган ел Нгамбо исемле Африка кызына өйләнгән татар егете Марат Дәүләевне хәтерлисезме? Яшь гаилә сөенечле яңалыгы белән уртаклашты: аларның кызлары туган. Бу хакта Марат социаль челтәрләрнең берсендә хәбәр итте.

Фотога төшәр өчен, «счет»ларын түләгәннәр. Җырчылар Гүзәл Уразова һәм Илдар Хәкимов белән фотога төшү өчен кеше нәрсәгә әзер дисезме? Бер ресторанда, мәсәлән, аларның ашаган ризыклары өчен түләгәннәр. Җырчылар югалып калган, билгеле. Фотога без болай да төшәбез, дип, мондый кунакчыллык өчен рәхмәт белдергәннәр.

Эльмира Кәлимуллина татар сәхнәсеннән китә? Бу көннәрдә «Голос» проекты җиңүчесе Эльмира Кәлимуллина Россия дәрәҗәсендәге музыкаль индустриягә аяк басарга җыенуын хәбәр итте. «Мин бу курку хисеннән тәмам арыдым. Минем үз урынымда буласым килә», – дип язган ул. Ә татар сәхнәсеннән киту-китмәве турында берни дә әйтмәгән.

СӘГАТЕ КАЙЧАН СУГА?

Узган сәхифә темасын дәвам итеп, бу юлы гүзәл затларыбыз белән сөйләштек. Статистика да шул турыда сөйли, болай да күреп торабыз: кызлар да гаилә корырга бик ашыкмый. Бүген кияүгә чыгуның яше бармы? Бу турыда гел искә төшереп торучыларга ни дип җавап бирергә?

Зәринә ХӘСӘНШИНА, җырчы:

Бу сорауны көн саен ишетәм, әле яшьне дә искә төшерәләр, җитмәсә. Ләкин һәр кешенең – үз вакыты. Шәхсән миңа килгәндә, бәлки, башка максатларны беренче урынга кую да тәэсир иткәндер, чөнки мин беркайчан да кияүгә чыгуны зур хыял һәм иң зур телә-гем итеп күрмәдем. Хәзерге заманда «һәр кеше үзе өчен», «син үзеңне сайларга тиеш», «син тормышыңда беренче» кебек кагыйдәләргә нигезләнгән тенденция китте. Бәлки, без, теләсәк тә, теләмәсәк тә, замана карашларына ияреп барабыздыр. Хатын-кыз хәзер ир-аттан да көчлерәк, уңышлырак булырга һәм күбрәк акча эшләргә тырыша. Аның максатлары башка, ул һәрвакыт үз өстендә эшли. Бер яктан, бу яхшы, син шәхес буларак үсәсең, ә икенче яктан, гаилә кору һаман саен арткы планга күчә...

Айзилә БАТЫРХАНОВА, «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе журналисты:

Гаилә институты егетләргә гаилә мөнәсәбәтләренә җаваплы карарга өйрәтсә, кызлар да кияүгә чыгу вакытын, тормыш коруны тизләтер иде, дип уйлыйм. Соңгы вакытта кияүдәге хатын-кызларга да тормышны үзләренә алып барырга туры килә. Шуңа да гаиләне алып барырдай ир-ат буласына 100 процент ышаныч белән генә кияүгә чыгу яклымын. «Кияүгә чыгасыңмы әле?» – дип сорыйлар, мин: «Аллаһыдан вакыты җитмәгән», – дип җавап бирәм. Бу чыннан да шулай, никах сәгате сукмаса, аны ашыктырудан мәгънә юк. Әмма сәгать сукканын көтеп утыру да дөрес түгел, дияргә – як-ягыма карап йөрим. Теләгем шул: иң мөһиме – кешелекле, гаилә һәм бала җанлы ир-ат булсын! Һәм әтиемә охшаган булсын иде!

Зәринә АСЫЛКАЕВА, җырчы:

Кияүгә чыгарга теләгән бик күп чибәр һәм уңышка ирешкән кызларны беләм. Миңа калса, вакыты җитмәгәндер. Һәркемнең – үз язмышы, кемдер башта карьера турында уйлый, шуңа күрә ашыкмый, ә кемдер әле үз мәхәббәтен очратмаган. «Кияүгә чыгарга кирәк», – дип, күбесенчә әти-әнием генә әйтә. Аларга чын мәхәббәтемне очраткач, шундук кияүгә чыгачагымны әйттем. Дөресен әйткәндә, гаиләле буласым килә инде...

Гөлинә ШӘЙХИ, «Китап» радиосының тапшырулар мөхәррире:

Миңа ул сорауны еш бирәләр дип әйтмәс идем. Холыкны белгәнгә күрә, алай туры бәреп сораучы юк. Кешене һәрвакыт сиңең иҗатыңа караганда, шәхси тормышың күбрәк кызыксындыра, бу – нормаль күренеш. Андыйларга мин гел: «Чакырмаган җиргә бармыйм мин», – дип кенә җавап бирәм. Ә ул сорауга җитдирәк карасак, яраткан кешемне тапкач та чыгачакмын, насыйп булса. Гаилә кору – минем өчен зур җаваплылык. Иң беренче чиратта мин гел: «Аны бәхетле итә алырмынмы?» – дип уйлыйм. Синең кулда – кеше язмышы. Яратмыйча яшәгән һәм хәтта яратуның ни икәнен белмәгән парлар барлыгын да беләм. Бу – минем өчен иң куркыныч әйберләрнең берсе. Ә әлегә минем күңел буш. Эзләп табасы иде!..

Сүз уңаеннан, узган ел Татарстанда бер мең өйләнмәгән ир-атка 1141 кияүдә булмаган хатын-кыз туры килгән. Республиканың ЗАГС идарәсе тәкъдим иткән рәсми саннарга караганда, Татарстанда яшәүче хатын-кызлар беренче сабыйларын күбесенчә 25–29 яшь аралыгында алып кайта.

Лилия ГЫЙМАЗОВА, Ләйсән САФИНА әзерләде

6 март | Чәршәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.05 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «МӘХӘББӘТ ХАКЫНА» 16+
11.00 «Выборы-2024» 12+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00, 00.25 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Азбука долголетия» 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я» 12+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.30 «Кызган казан» 6+
18.00 «Гаилә учагы» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Соотечественники» 16+
23.00 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
00.00 «Каравай» 6+
01.15 «Кәмит Җәвит» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Башваткыч» 12+
05.35 «Онытa алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 21.25 «Муза… Музыка… Мозаффаров…» 16+
09.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
10.00 «Халкым минем» 12+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 04.20 «Сөйләшергә вакыт» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00, 19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
18.20, 23.10 «Кәмит Җәвит» 16+
20.00, 00.15 «Гаилә учагы» 16+
03.30 «Күңелем назлары җырымда чагыла» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.00 Церемония закрытия Всемирного фестиваля молодёжи 2024
21.00 «Время»
22.00 «СОЮЗ СПАСЕНИЯ» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 «Мой друг Жванецкий» 12+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.35, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
15.00 «Судьба человека» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «АННА МЕДИУМ» 16+
23.30 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.10 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.50 «Кто кого?» 12+
06.30 Фрирайд. Мировой тур 6+
07.00, 10.10, 12.55, 14.45, 16.40 Новости
07.05, 15.40, 01.00 Все на Матч!
10.15, 15.20 Специальный репортаж 12+
10.35, 19.20 Футбол. Лига чемпионов. Обзор 6+
11.45 Бокс. Bare Knuckle FC. Джейд Массон-Вонг против Габриэль Роман 16+
13.00 «Есть тема!»
14.15 «Вид сверху» 12+
16.45 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. 1/8 финала
20.30 Футбол. Лига Европы. 1/8 финала. «Спортинг» – «Аталанта»
22.40 Футбол. Лига чемпионов. 1/8 финала
04.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. ЦСКА – УНИКС 6+

НТВ

04.50 «ПАСЕЧНИК» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «СЕВЕРНАЯ ЗВЕЗДА» 16+
00.55 «ОДИН ПРОТИВ ВСЕХ» 16+
02.40 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ

07.25, 04.50 «Давай разведёмся!» 16+
08.25, 03.10 «Тест на отцовство» 16+
10.40, 23.45 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.50 «Порча» 16+
12.55, 01.50 «Знахарка» 16+
13.30, 02.15 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.45 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Кризисный центр» 16+
19.00 «НЕ БОЙСЯ, ВЕРЬ, ЛЮБИ» 16+
23.20 «Уютное утро» 16+
05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

07.00 «Сегодня утром» 16+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 01.00 «СУДЬБА» 16+
12.35, 18.50 «Специальный репортаж» 16+
13.25, 03.15 «КОМИССАРША» 16+
15.00 Военные новости 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Секретные материалы» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «БАРМЕН ИЗ «ЗОЛОТОГО ЯКОРЯ» 12+
02.10 «Автомобили в погонах» 16+
02.50 «Хроника Победы» 16+

7 март | Пәнҗешәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «МӘХӘББӘТ ХАКЫНА» 16+
11.00 «Выборы-2024» 12+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00, 04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
14.00 «Память сердца» 16+
14.15 «Азбука долголетия» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.30, 00.25 «Точка опоры» 16+
19.00, 01.40 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Погружение на 100» 12+
21.10 «Наши герои» 16+
23.00 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
01.15 «Кто мы татары?» 12+
02.05 «Аклык» 12+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.35 «Онытa алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05 «Манзара» 16+
08.00, 00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 04.20 «Кәмит Җәвит» 16+
09.30 «Гаилә учагы» 16+
10.00, 20.00 «Кызган казан» 6+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00, 19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
18.20, 23.10 «Сөйләшергә вакыт» 16+
21.25 «Күңелем назлары җырымда чагыла» 16+
01.05 З.Хәким. «Бармы ришвәтлән дәва?» Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
07.55 Выборы-2024
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
18.40 «Человек и закон» 16+
19.45 «Поле чудес» 16+
21.00 «Время»
22.00 «СОЮЗ СПАСЕНИЯ» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 «Мой друг Жванецкий» 12+
00.55 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.35, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
15.00 «Женщины. Война» 16+
16.30 «Прямой эфир» 16+
21.20 «АННА МЕДИУМ» 16+
23.30 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.10 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «УКРОЩЕНИЕ СВЕКРОВИ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.50 «Кто кого?» 12+
06.30 «Вид сверху» 12+
07.00, 10.10, 14.45, 16.40 Новости
07.05, 15.40, 20.15, 01.00 Все на Матч!
10.15, 15.20 Специальный репортаж 12+
10.35, 16.45 Футбол. Лига чемпионов. Обзор 6+
11.45, 17.55 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. 1/8 финала
14.15 «Большой хоккей» 12+
20.30 Футбол. Лига Европы. 1/8 финала
04.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «ПАРМА» – «Зенит» 6+

НТВ

04.55 «ПАСЕЧНИК» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «Прошу, прости!» 16+
17.55 «Жди меня» 12+
20.00 «СЕВЕРНАЯ ЗВЕЗДА» 16+
00.00 «Своя правда» 16+
02.05 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ

07.15, 04.30 «Давай разведёмся!» 16+
08.15, 02.50 «Тест на отцовство» 16+
10.30, 23.15 «Понять. Простить» 16+
11.40, 00.30 «Порча» 16+
12.55, 01.30 «Знахарка» 16+
13.30, 02.00 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.25 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Кризисный центр» 16+
19.00 «ПОВОРОТ СУДЬБЫ» 16+
05.20 «По делам несовершеннолетних» 16+
06.10 «Будни ЗАГСа» 16+

ЗВЕЗДА

07.00 «Сегодня утром» 16+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 01.00 «С ТОБОЙ И БЕЗ ТЕБЯ…» 12+
12.50, 18.50 «Специальный репортаж» 16+
13.25, 15.05, 17.15, 02.25 «КОМИССАРША» 16+
15.00 Военные новости 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Код доступа» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «БЕРЕГИТЕ МУЖЧИН!» 12+

8 март | Җомга

ВГТРК ТАТАРСТАН

21.15 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «УЕННАН УЙМАК» 16+
11.20 «Актуальный ислам» 16+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00, 01.55 «Кояш гомере» 12+
14.30 «Туган җир» 12+
15.00 Габделфәт Сафинның юбилей концерты 12+
18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре 16+
19.00 «Мин бәхетле» 12+
19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
20.00 «Яратып яшик!» 12+
21.00 «Саф хисле мәхәббәт» 12+
22.00 Финал конкурса «Мисс Татарстан-2024» 12+
01.05 «Семь дней +» 16+
01.30 «Соотечественники» 16+
03.55 «Башваткыч» 12+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Онытa алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Рәхәт концерт-show» 16+
07.30 «Шаян хәлләр» 16+
08.30 «Әниләр һәм бәбиләр» 12+
10.30, 16.30, 00.15 «Нәсыйхәт» 16+
11.00, 17.30, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 З.Хәким. «Килә ява, килә ява». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
15.00, 18.00, 21.30 «Яңалыклар» 16+
15.25, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
17.00 «Туган җир» 12+
18.20 Габделфәт Сафинның юбилей концерты 16+
21.55 Н.Исәнбәт. «Гөлҗамал». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
01.05 Д.Салихов. «Капчык». Әлмәт татар дәүләт драма театры спектакле 16+
03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
04.20 «Ком сәгате» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

06.00, 10.00, 12.00 Новости
06.10 «Моя любовь» 12+
06.40 «САМАЯ ОБАЯТЕЛЬНАЯ И ПРИВЛЕКАТЕЛЬНАЯ» 12+
08.10 «ВЕСНА НА ЗАРЕЧНОЙ УЛИЦЕ» 12+
10.15 «ДЕВЧАТА» 0+
12.15 «Империя: Екатерина II» 12+
16.30 Праздничный концерт в Кремле 12+
18.00 Вечерние новости
19.00 «ЛЮБОВЬ И ГОЛУБИ» 12+
21.00 «Время»
21.35 «Голос» 12+
23.20 «9 1/2 НЕДЕЛЬ» 18+
01.35 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

09.20 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 17.00, 20.00 Вести
12.00 «О чём поют 8 Марта»
14.00 «СЛУЖЕБНЫЙ РОМАН» 12+
17.50 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «Ну-ка, все вместе! Хором!» 12+
00.45 «ЛЁД» 12+
02.45 «ЛЮБОВЬ БЕЗ РАЗМЕРА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Кто кого?» 12+
06.30 «Большой хоккей» 12+
07.00, 09.35, 16.40 Новости
07.05, 16.00, 20.30, 22.15, 00.45 Все на Матч!
09.40 «Небесная грация» 0+
10.00 «НЕФУТБОЛ» 12+
11.55 Мини-футбол. Чемпионат России. ПАРИ-Суперлига. «Синара» – «Газпром-Югра»
13.45 Футбол. МИР РПЛ. «Крылья Советов» – ЦСКА
16.45 Футбол. Еврокубки. Обзор 6+
18.15 Футбол. МИР РПЛ. «Ростов» – «Краснодар»
21.00 Бетсити. Вечер профессионального бокса. Алексей Папин против Остина Ннамди
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Наполи» – «Торино»
01.30 «Формула-1. Гаснут огни» 12+
02.00 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Динамо» – «Газпром-Югра» 6+
04.00 Смешанные единоборства. One FC

НТВ

04.20 «ДЕКАБРИСТКА» 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
15.15 «ИМПЕРАТРИЦЫ» 12+
19.25 «Маска» 12+
23.15 «Как? Разве вам ничего не говорили?» 16+
01.00 «СИЛЬНАЯ» 16+
02.40 «Квартирный вопрос» 0+
03.35 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.55, 03.15 «ОДНАЖДЫ ДВАДЦАТЬ ЛЕТ СПУСТЯ» 16+
08.30, 04.30 «МОЛОДАЯ ЖЕНА» 16+
10.30 «КАК ИЗВЕСТИ ЛЮБОВНИЦУ ЗА 7 ДНЕЙ» 16+
14.40 «ЖЕНСКИЙ ЗАЩИТНИК» 16+
19.00 «ОДНО ЦЕЛОЕ» 16+
23.20 «ПРОШУ ПОВЕРИТЬ МНЕ НА СЛОВО» 16+
06.05 «6 кадров» 16+
06.15 «МАЧЕХА» 16+

ЗВЕЗДА

05.45 «УВОЛЬНЕНИЕ НА БЕРЕГ» 12+
07.25 «Легенды армии» 12+
09.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15 «В знании – сила, в красоте – спасение, в служении – судьба» 16+
09.55 «РАЗНЫЕ СУДЬБЫ» 12+
12.05, 13.20 «РАЗРЕШИТЕ ТЕБЯ ПОЦЕЛОВАТЬ» 16+
14.35 «РАЗРЕШИТЕ ТЕБЯ ПОЦЕЛОВАТЬ… СНОВА» 16+
17.00 «РАЗРЕШИТЕ ТЕБЯ ПОЦЕЛОВАТЬ… НА СВАДЬБЕ» 16+
19.20 «РАЗРЕШИТЕ ТЕБЯ ПОЦЕЛОВАТЬ… ОТЕЦ НЕВЕСТЫ» 16+
21.20 «Специальный репортаж» 16+
22.00 «Здравствуйте, товарищи!» 16+
23.30 «Музыка+» 12+
00.55 «ОБЫКНОВЕННОЕ ЧУДО» 12+
03.15 «ПРЕДЛАГАЮ РУКУ И СЕРДЦЕ» 12+
04.45 «ПОДКИДЫШ» 6+

9 март | Шимбә

ТАТАРСТАН

08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+
07.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 16+
09.00, 03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00 «Туган авылым» 12+
11.30, 01.15 «Музыкальный майдан» 16+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
13.30 «Гаилә учагы» 16+
14.00 «Әлдермештән Әлмәндәр» 12+
15.15 Концерт 12+
16.30 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
17.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
18.00, 04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
19.30, 21.30 Новости в субботу 16+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «ЛЮБОВЬ С ПЕРВОГО ВЗДОХА» 16+
23.45 «ЛЮБИТЬ НЕЛЬЗЯ ЗАБЫТЬ» 16+
01.40 «Семь дней +» 16+
02.05 «СӨЮ КӨТӘ ЙӨРӘК» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
05.35 «Онытa алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
07.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 16+
09.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00, 18.15, 03.00 «Башваткыч» 12+
12.05, 19.05, 03.50 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Аклык» 12+
17.15 «Казаннан Казанга» 16+
17.45, 05.05 «Халкым минем» 12+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Кояш гомере» 12+
22.35 Т. Миңнуллин. «Алты кызга бер кияү». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
00.40 «БИЧАРАКАЙ» 18+
04.40 «Заман көзгесе» 6+
05.30 «Нәсыйхәт» 16+

1 КАНАЛ

06.00 «Доброе утро. Суббота»
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00, 12.00 Новости
10.15, 23.10 «Звезда по имени Гагарин» 12+
11.05, 00.10 «Человек, сошедший с небес» 12+
12.15 «Поехали!» 12+
13.10 «Империя: Анна Иоанновна» 12+
14.20 «Империя: Елизавета Петровна» 12+
16.25 «Эксклюзив» 16+
18.00 Вечерние новости
18.20 «Сегодня вечером» 16+
19.55 Турнир сильнейших фигуристов
21.00 «Время»
01.05 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

04.20 «ТРЕТЬЯ ПОПЫТКА» 12+
06.00 «ПРАЗДНИК РАЗБИТЫХ СЕРДЕЦ» 12+
08.00 Вести. Местное время
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 17.00, 20.00 Вести
11.40 «СЛУЖЕБНЫЙ РОМАН» 12+
14.35 «Измайловский парк» 16+
17.50 К 50-летию Юрия Шатунова
21.00 «СИНДРОМ ОТЛОЖЕННОГО СЧАСТЬЯ» 16+
22.55 «ЛЁД 2» 6+
01.15 «ЖЕНЩИНЫ» 12+
04.30 «НИНКИНА ЛЮБОВЬ» 12+

МАТЧ ТВ

08.00, 10.10 Новости
08.05, 13.45, 16.45, 19.25, 00.45 Все на Матч!
10.15 «Команда МАТЧ» 0+
10.30 Синхронное плавание. XX Шоу олимпийских чемпионов 0+
11.55 Мини-футбол. Чемпионат России. ПАРИ-Суперлига. «Тюмень» – ЛКС
14.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. 1/8 финала
17.25 Футбол. Суперлига. Женщины. «Зенит» – «Спартак»
20.00 Смешанные единоборства. АСА
22.40 Футбол. Чемпионат Италии
01.30 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 6+
02.00 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Белогорье» – «Кузбасс» 6+
04.00 Триатлон. Мировая серия 0+

НТВ

05.20 «ПАСЕЧНИК» 16+
06.55 «Жди меня» 12+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «Поедем, поедим!» 16+
09.20 «Едим дома» 0+
10.20 «Главная дорога» 16+
11.00 «Живая еда» 12+
12.00 «Квартирный вопрос» 0+
13.00 «Основано на реальных событиях» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «ЧП. Расследование» 16+
17.00 «Следствие вели…» 16+
19.00 «Центральное телевидение»
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.20 «Звезды» 16+
23.25 «Международная пилорама» 18+
00.15 «Летать – так летать» 16+
01.50 «Дачный ответ» 0+
02.45 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+
03.15 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ

09.50 «Уютное утро» 16+
10.15 «Я НЕ ТВОЯ» 16+
14.35 «ПАУЧИЙ ИСТОЧНИК» 16+
19.00 «ДОБРОТА» 16+
22.45 «КАК ИЗВЕСТИ ЛЮБОВНИЦУ ЗА 7 ДНЕЙ» 16+
02.25 «Жизнь после Ванги» 16+
05.40 «6 кадров» 16+
05.55 «ПРОШУ ПОВЕРИТЬ МНЕ НА СЛОВО» 16+

ЗВЕЗДА

06.00 «МАМА» 6+
07.55 «Морской бой» 6+
09.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
09.20 «СУМКА ИНКАССАТОРА» 12+
11.10 Мужики 16+
11.40 «СССР. Знак качества» 12+
12.30 «Не факт!» 16+
13.15 «Легенды науки» 12+
14.00 «Главный день» 16+
14.50 «Время героев» 16+
15.10, 19.25 «ДОЛГАЯ ДОРОГА В ДЮНАХ» 12+
02.30 «РАЗНЫЕ СУДЬБЫ» 12+
04.15 «Незабудки. Бессмертный авиаполк» 16+

10 март | Якшәмбе

ТАТАРСТАН

08.00 Местное время. Воскресенье

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 00.45 «Син минем тиң ярым» 12+
08.00, 13.00 «Адымнар» 16+
08.30 «Тархан» 6+
09.00 Мультфильмы 6+
09.15 «Тамчы-шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 0+
10.15 «Кызган казан» 6+
11.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество» 16+
13.30 «Погружение на 100» 12+
13.40 «Татар сүзе» 12+
14.00 «Рәхәт концерт-show» 16+
16.00 «Ком сәгате» 16+
17.00 «Видеоспорт» 16+
17.30 «Соотечественники» 16+
18.00 «Башваткыч» 12+
19.00, 22.00 «Семь дней» 16+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты 16+
21.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
23.00 «ПАДЕНИЕ ТОКИО» 12+
02.00 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Онытa алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Заман көзгесе» 6+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять»
07.00 «Адымнар» 16+
07.30 «Кто мы татары?» 12+
08.00 Г.Камал. «Беренче театр» 16+
09.00, 03.40 «Күңелем назлары җырымда чагыла…» 16+
10.00 «Кызган казан» 6+
10.30 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05, 00.40 «Яшьләр тукталышы» 6+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00, 04.35 «Гаилә учагы» 16+
13.30 «Туган көн концерты – 35!» 16+
16.45, 02.45 «Шаян хәлләр» 16+
17.15, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит» 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате» 16+
20.00 «Семь дней» 16+
21.50 М.Кәрим. «Ай тотылган төндә». Чаллы татар дәүләт драма театры спектакле 16+
01.05 «Манзара» 16+
03.15 «Әдәби хәзинә» 6+
05.00 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

06.00, 10.00, 12.00 Новости
06.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.40 «Часовой» 12+
08.10 «Здоровье» 16+
09.20 «Мечталлион» 12+
09.40 «Непутевые заметки» 12+
10.15 «Играем свадьбу!» 12+
11.05 «Жизнь других» 12+
12.15 «Повара на колесах» 12+
13.10 «Видели видео?» 0+
14.30 «БЛАГОСЛОВИТЕ ЖЕНЩИНУ» 12+
16.50 «Берёзка». Красота по-русски 12+
18.00 Вечерние новости
19.00 «Лучше всех!» 0+
21.00 «Время»
23.00 «АБРЕК» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

06.15, 02.00 «СОСЕДИ ПО РАЗВОДУ» 12+
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома»
09.25 «Утренняя почта»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 17.00 Вести
12.00 «Большие перемены»
13.00 «ЮЖНЫЙ ЦИКЛОН» 16+
17.50 «Песни от всей души» 12+
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.05 «Женщины. Война» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 Смешанные единоборства
09.00, 10.10, 13.00 Новости
09.05, 13.05, 16.00, 19.15, 00.45 Все на Матч!
10.15 «Спорт Тоша» 0+
10.30 «Криштиану Роналду: Единственный и неповторимый» 12+
11.55 «Вы это видели» 12+
13.45 Футбол. МИР РПЛ. «Оренбург» – «Балтика»
16.45 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. 1/8 финала
19.55, 22.40 Футбол. Чемпионат Италии
22.00 После футбола
01.30 Фрирайд. Мировой тур 6+
02.00 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Локомотив» – «Енисей» 6+
04.00 Триатлон. Мировая серия. Смешанная эстафета 0+

НТВ

04.50 «ПАСЕЧНИК» 16+
06.30 «Центральное телевидение» 16+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача» 16+
11.00 «Чудо техники» 12+
12.00 «Дачный ответ» 0+
13.00 «НашПотребНадзор» 16+
14.05 «Однажды…» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «Человек в праве» 16+
17.00 «Следствие вели…» 16+
18.00 «Новые русские сенсации» 16+
19.00 «Итоги недели»
20.20 «Маска» 12+
00.00 «Звезды сошлись» 16+
01.35 «Основано на реальных событиях» 16+
03.10 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ

09.55 «Пять ужинов» 16+
10.10 «БОКАЛ ВИНА И АПЕЛЬСИНЫ» 16+
14.40 «ШАМАНКА» 16+
19.00 «ДОБРОТА» 16+
22.50 «МАЧЕХА» 16+
02.25 «Настоящая Ванга» 16+
06.20 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.35, 01.40 «ПОСТАРАЙСЯ ОСТАТЬСЯ ЖИВЫМ» 12+
06.55 «РЫСЬ» 16+
09.00 «Новости недели» 16+
09.25 «Служу России» 16+
09.55 «Военная приемка» 16+
10.40 «Легенды армии» 12+
11.30 «Моторы и колеса» 12+
12.20 «Война миров» 16+
13.10 «Код доступа» 16+
14.00 «Улика из прошлого» 16+
14.50 «Скрытые угрозы» 16+
15.40 «Секретные материалы» 16+
16.30 «Загадки века» 12+
17.20 «Специальный репортаж» 16+
18.00 Главное 16+
19.45 «Легенды советского сыска» 16+
23.00 «Фетисов» 12+
23.50 «СУМКА ИНКАССАТОРА» 12+
02.45 «УВОЛЬНЕНИЕ НА БЕРЕГ» 12+
04.15 «Часовые памяти» 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген тәэмин итүдәге казанышлары өчен Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы бүлек җитәкчесе **Сәйфуллина** Гөлназ Марсель кызына Россия Федерациясе Президенты боерыгы нигезендә **Россия Федерациясе Президенты Рәхмәте** белдерелде.

***

Мәгариф, девиант тәртипкә ия булган балаларны тәрбияләү һәм социализацияләү өлкәсендәге казанышлары өчен **«Раифа ябык типтагы махсус укыту-тәрбия учреждениесе» федераль дәүләт бюджет профессиональ белем бирү учреждениесе коллективына** Россия Федерациясе Президенты боерыгы нигезендә **Россия Федерациясе Президенты Рәхмәте** белдерелде.

***

Татарстан Республикасының мәдәни һәм рухи мирасын саклауга һәм баетуга зур өлеш кертүләре өчен Башкортостан Республикасының «Берлек» мәдәни-мәгърифәти төбәк иҗтимагый оешмасы әгъзасы **Әсәдуллин** Рәил Мирвәй улы, Чаллы шәһәренең «Энергетик» мәдәният сарае» муниципаль автоном мәдәният учреждениесенең клуб учреждениесе методисты **Рзаева** Гөлзадә Мөхәммәтгәрәй кызы, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Р-АГРО» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Зиатдинов** Раил Шагартдин улы, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исемендәге Археология институты» аерымланган структур бүлекчәсе географик мәгълүмат технологияләре бүлеге мөдире **Сәйфетдинова** Гүзәл Марат кызы, Чаллы шәһәренең «6 номерлы «ДА-ДА» балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль автоном өстәмә белем бирү учреждениесе (архитектура-дизайн юнәлешендәге) укытучысы **Яковлева** Лилия Шәүкәт кызы, физик культураны һәм спортны үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Олимп» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү мәгариф учреждениесенең чаңгы ярышлары буенча тренеры-укытучысы **Мильчаков** Владиленин Николаевич, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм эшендә уңышларга ирешүе өчен «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениесе производство-хуҗалык бүлегенең эш бүлмәләрен җыештыручысы **Халикова** Гөлфия Абдулла кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«2 номерлы стоматология поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 2 номерлы стоматология бүлекчәсе мөдире, табиб – стоматолог-терапевты (Чаллы шәһәре) **Егорова** Ольга Евгеньевнага, «Биектау үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең хирургия бүлекчәсе табибы – анестезиологы-реаниматологы **Касыймов** Шамил Шәмсерахман улына, «Мамадыш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең поликлиника педиатрия бүлекчәсе участок табиб-педиатры **Музлова** Надежда Викторовнага, «Әлмәт үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең кардиология бүлекчәсе мөдире – табиб-кардиологы **Талипов** Мөсәвир Габделхәй улына, «Азнакай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе ультратавыш ярдәмендә диагноз кую кабинетының ультратавыш ярдәмендә диагноз кую табибы **Хаҗиәхмәтов** Илшат Җәүдәт улына, «Балык Бистәсе үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе поликлиникасының дерматовенерология кабинеты табиб-дерматовенерологы **Шакиров** Айрат Рәфкать улына **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары **Сәхипова** Индира Рәис кызына **«Татарстан Республикасының атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Советлар Союзы Герое Нәбиулла Шәфикъ улы Зиннуров исемендәге Югары Ослан гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Айзатвафина** Зегря Гомәр кызына, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Мүлмә урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең физика укытучысы **Әхмәтҗанова** Флюра Рәфгать кызына, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Носы төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Бәдертдинов** Вәсим Хәмит улына, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Дементьев Василий Степанович исемендәге Алешкин-Саплык урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган (чуаш) тел һәм әдәбият укытучысы **Григорьева** Надежда Васильевнага, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Питрәчнең 2 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең математика укытучысы **Долгова** Любовь Петровнага, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының 2 номерлы лицее муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең математика укытучысы **Журавлева** Татьяна Александровнага, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Советлар Союзы Герое Алексей Петрович Исаев исемендәге Макыл урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең география һәм химия укытучысы **Зыятдинова** Светлана Әкрәм кызына, Чаллы шәһәренең «Тылсымчы кыз» 83 номерлы балалар бакчасы – баланы үстерү үзәге» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе тәрбиячесе (балаларны туган телгә өйрәтү буенча) **Кидрячева** Раушания Гайнулла кызына, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Яңа Элмәле урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Мельникова** Татьяна Васильевнага, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Күтәмә урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Миронов** Александр Витальевичка, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Суыксу төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Сәйфуллина** Гүзәл Нурислам кызына, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Яңа Әлем төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныфлар укытучысы **Сәрвәрова** Фирая Мөбарәк кызына, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Көек-Ерыкса урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең география һәм химия укытучысы **Фәләхиев** Гафур Хәтим улына **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Язучы сүзе

Кызык

Казанда чакта мин эш арасында бераз җәяү йөреп кирәргә яратам. Көн әйбәт булганда, урамнарны әйләнәм, яңгыр-буранда яки салкын вакытта метро станциясендә йөрим. Җиңү проспектында уңайлы итеп эшләнгән ул, һич ялыкмыйча, берничә чакрым урарга була.

Менә шунда йөргән чакта бер егет Җиңү скверына чыгу юлын сорады. Өйрәтеп җибәрдем. Әйләнеп, икенче якка китсәм, беркадәр вакыттан соң тагын теге егет. Яшь кенә ул үзе, унтугыз-егерме тирәсендәдер. Озын буйлы, төз гәүдәле. Пөхтә киенгән. Читтән карауга ук затлы булып тора. Очынып-кылтаеп, юлдан язып йөри торган кебек түгел. Үз-үзен тотышында да яктылык, ягымлылык чагылып китә. Мин аны күргәч, сәерсенеп игътибарлабрак караганмылдыр инде, ул тагын яныма килде дә шул ук сорауны бирде. Мин сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куйдым, әмма, аны-моны сиздермичә, бик тәгәл итеп өйрәтеп җибәрдем.

Казанның иң рәхәт бер үзенчәлеге бар аның. Монда кемнән генә адрес сорасаң да, бер иренмичә, бөртекләп өйрәтә. Үзе белмәсә, телефонын актарып, сиңа кирәкле җирне табып бирә. Яше дә, карты да шундый. Күченеп килгән вакытларда мин еш сораша торган идем, шуңа яхшы беләм. Менә шул гадәт кенә дә Казан халкына чиксез бер мәхәббәт уята. Бик күп җирләрдә булганым бар, бөтенесендә дә болай түгел ул. Казан – үзенә бертөрле, ярдәмчел шәһәр. Хәзер үземнән дә сорыйлар, мин дә өйрәтеп җибәрәм. Аллага шөкер…

Шулай уйланып килгәндә, теге егет кабат очрады. Бу юлы сорамыйча гына узып китте. Метрода адашып, әллә ничәшәр кабат әйләнеп йөрүчеләр булыштыра ул. Тик күбесенчә авылдан килгән өлкән яшьтәге кешеләр шулай итә. Яшьләр түгел. Ә бу егет авылныкы түгел инде, монысы әллә кайдан күренеп тора. Шуңа бераз сәерсенеп карап тордым да аны үзем туктаттым.

– Сез Җиңү скверын эзлисез бугай?

Егет миңа күтәрелеп карады. Керсез саф караш. Махмырдан да түгел, башка химикат та кулланмаган дип әйтүем. Андый кешенең карашы эт күзләре кебек моңсу була. Күңелендәге бөтен моң-зары, бөтен үкенече күзләренә чыга бугай. Күзләрне күңел көзгесе дип әйтәләр бит инде. Хәрам нәрсә кулланучыларның әнә шул көзгесе яки ватык, яки парлы була. Моныкы чип-чиста иде. Бары тик, ә сез минем ни эзләгәнне каян белдегез, дигәндәйрәк гаҗәпсенү бар.

Мин дә шул якка атлый идем. Иярттем моны. Дәшми-тынмый бармас өчен генә кайда эшләвен сорашкан булдым. Программист икән. Бу өлкә миңа да күпмедер таныш, бер-ике сорау биреп карадым. Теләмичә генә җаваплагач, эч пошырып тормадым.

Шулай да баскычтан менгәндә чайкалып киткәч, мин аның адымнарының хәлсезлегенә игътибар иттем. Ул моны сизеп, уңайсызланды бугай, турырак атларга тырышты. Туры атларга тырышкан кешедән дә ныграк чайкалучы булмый. Шуңа мин кайсы йортка баруын сорадым. Әйтте. Мин дә шул якка бит, дигән булып, моны подъездына кадәр озатып куйдым. Килеп җиткәч: «Үзең менә аласыңмы?» – дип тә сорадым. Ул баш какты. Мин ары киттем.

Шуның белән бетте бу. Онытылды. Истә калырлыгы юк та бит инде.

Әле менә электрон почтаны актарып утырам. Бер егет нәкъ миңа кирәкле скрипт (кечкенә программа) язып җибәргән. Мине интернет аша табуын әйткән. «Сайтыгызны карадым, анда менә шушы скриптны куллансагыз, җайлырак булачак. Сорауларыгыз булса, языгыз. Мин бик теләп ярдәм итәрмен. Ә теге чакта озатып куйганыгыз өчен рәхмәт. Ул көнне «ашыгыч ярдәм» чакырырга туры килде, микроинсульт булган», – дигән.

Әйбәтлегемне күрсәтү өчен язмыйм әле монысын. Күп очракта без игътибарсыз булабыз бит инде. Ишетмибез дә, күрмибез дә. Менә шушы игътибарсызлыгыбыз белән күпме кешене авыр хәлгә куябыз, коткарырга мөмкин булганнарны коткармыйча калабыз икән?

Марат КӘБИРОВ

КУРКЫНЫЧ ПРОЦЕНТЛАР

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

Төркиянең «ASAM» (Евразия стратегик тикшеренүләр үзәге) директоры Әрай Гүчлүәр үткән атнада: «Британия үз планнары буенча хәрби структурлаштыруны – 2028 елга, ә АКШ 2030 елга төгәлләячәк. Шул датадан соң алар зур сугышка әзерләнә. Төркиянең үз оборона сәнәгатен тизләтүенең төп сәбәпләренең берсе шул: 2030 елга әзерлек», – диде.

Чынлап та, төрекләр ашыга. Берничә көн элек алар үзләренең бишенче буын истребителе KAANны беренче тапкыр һавага күтәрде. Самолетны эшләүче компания директоры Темел Котил: «Беренче очыш бик мөһим иде. 25 тонналык җайланма. Без – дөньяда бишенче буын юк итүче очкычлар җитештерүче дүртенче ил… F-22 һәм F-35 самолетларына караганда югарырак технологияләрне сайладык», – диде. Үзебездән өстәп, шуны әйтик: KAANның беренче очышы бөтен дөньяда зур яңгыраш алды, чөнки төрекләр әйтүенчә, һава сугышында аңа каршы чыккан бер генә очкыч та җиңүгә һәм исән калуга өметләнә алмый. Беренче очыш армия самолетларга тиенде дигән сүз түгел әле, бары тик 2028 елга гына 20 очкыч җитештерелеп тапшырылачак.

Төрек оборона сәнәгатенең башка бик күп уңышлары бар, әмма минем максат алар турында сөйләү түгел. Кешелек дөньясы ни өчен шулкадәр зур сугышка ашкына, ул ни бирәчәк? Менә шул сорауларга бергәләп җавап эзлик. Сугыш гади халыкка күз яше һәм хәсрәттән башка берни дә бирми, әмма массалар, пропагандага алданып, барыбер үзара бугазлашу мәйданына ашкыначак.

Моннан унбиш еллар тирәсе элек зур сугышны берәү дә телгә алмый диярлек иде. Бары тик «ВТ» хәбәрчесе генә үз язмаларында кешелек дөньясының озакламый зур сугыш дигән фаҗига белән очрашачагын хәбәр итә, аның котылгысызлыгын раслый иде. Ул гына түгел, сугышның кай төбәкләрдә башланасын һәм ничегрәк барасын фаразлаган язмаларын бастыра иде. Төрек аналитигыннан аермалы буларак, зур канлы бәрелешнең 2030 елдан иртәрәк башлану куркынычы барлыгын да әйтә алам. Дөресен генә әйткәндә, бара бит инде сугыш, планетаның төрле почмакларында бара һәм төрекләр аңа бүген я турыдан-туры, я читләтеп катнашалар да. Һәм дөнья лидерлары, берсеннән-берсе узып, сугышның инде хәл ителгән мәсьәлә булуы турында белдерүләр ясый.

ru.freepik.com

Сугышның төп сәбәпчеләре – риба капиталында байлык туплаган олигархлар. Күпләр «олигарх» сүзе грек теленнән алынган дип саный. Рус әйтмешли: «Ничего подобного». Терминга нигезне гарәп сүзе «ал-җә'рих» бирә, татарчага күчергәч, ул «ерткыч» дигәнне аңлата. Кайсы гына миллиардерны алып карасак та, аның байлыкны финанс спекуляцияләре нәтиҗәсендә туплавын күрә алабыз, ул спекуляцияләрнең нигезендә процент капиталы – риба ята. Рәсми статистикадан күренгәнчә, Россиядә эшләүче гражданнарның 57 проценты кредит бурычларына баткан. Һәр улүче дүрт кешенең берсе нәселенә мирас итеп бурыч калдыра икән. Хәзер Россия закон чыгаручылары шул бурычны варислардан түләтү турында канун әзерләү хакында сөйләшә. Әлегә андый закон юк, ләкин барыбер банклар үлгән кешенең камытын варислары муенына киертү җаен таба. Тагын бер нәрсәне искәртик: Россия – халкы бурычка бату ягыннан ахыргы урыннарда торучы илләрнең берсе. Бездә гражданнарның бурычлары эчке тулай продуктның 25–28 процентын гына тәшкил итә («гына» кисәкчәсе сезне алдамасын, чынлыкта күрсәткеч бик зур). АКШта бу күрсәткеч – 75 процент, Канадада – 104, Көньяк Кореяда – 106. Гражданнарның бурычлары ил җитештергәннән артып китсә яисә аңа якынлашса гына да, бүтән кредит бирү мәгънәсезгә әйләнә, чөнки түли алмаячаклар. Гражданнар гына түгел, хөкүмәтләр дә бурычын түләрлек хәлдә түгел. АКШ хөкүмәте март башында янә шатдаунга килеп терәлде, ягъни чиновникларга түләргә акчасы юк. Конгресста бик көчле сайлау алды тартышы бара, шул сәбәпле республикачылар, демократларга үч итеп, бурычка акча бирү турында законга аяк чалды. Яңа әҗәтләр хисабына шатдауннан чыгарлар барыбер, ләкин бу катастрофаны кичектереп тору гына булачак.

Кредитларның тагын бер начар ягы бар: алар инфляцияне өскә куа. Үзәк банклар, төп ставканы күтәреп, инфляцияне авызлыкламакчы була, әмма бу булышмый. Аның булышмаячагын гап-гади арифметика белән раслап була. Бизнес һәм гражданнар хәзер кредит алмыйча алга бара алмый инде. Бүген иртән кредитлауны туктатсаң, глобаль капитализм кичкә үк җимереләчәк. Кредитлау туктамасын өчен, нәрсә кирәк? Дөрес уйлыйсыз: акча басарга. Бурычка бирү тәгәрмәчен бары тик эмиссия дигән нәрсә белән генә әйләндереп була. Акча бастыңмы, бәя үсәчәк, чөнки процентына карап тормыйча кредит алу өчен чиратлар тезеләчәк.

Дөньяда иң көчле инфляция һәм иң зур процент ставкасы булган ил кайсы әле? Аргентина. Аның популист Президенты Милей, ил бюджетындагы дефицитны каплау максатыннан акча басарга әмер биргән Үзәк банкның теләсә кайсы чиновнигын төрмәгә утырту турында закон проекты кертеп азаплана. Проект законга әверелсә, Аргентина икътисады санаулы көннәр эчендә җимереләчәк. Андый канун булмаганда, барлык илләрнең икътисадлары шулай ук җимереләчәк, ләкин соңрак, газаплы тартыштан соң. Менә шул җимерелү датасына олигархик капитал кубызына биегән лидерлар зур сугыш әзерли дә инде.

Укучылар сорау бирергә мөмкин: ә кредитсыз яшәп буламы соң? 2008 елда бу юлларның авторы «Риба һәм бәхет» дигән язма бастырган һәм анда процентлы бурычларның кешене һәлакәткә алып барачагын раслаган иде. Шул чакта газета сайтында укучыларның берсе: «Ә менә сез кредитсыз яшәп машина алган, йорт төзегән бер генә гади кешене мисалга китерә аласызмы?» – дип сорады. Аннан соңгы елларда безнең гаилә кредитсыз ике яңа машина сатып алды, ике йорт сафка бастырды. Юк, күп акча алып эшләмибез, әмма җәмгыятьтә процент капиталы хакимлек итмәсә, без матди яктан күпкә зуррак уңышларга ирешер идек. Улым белән беркөнне, аның яңа салынып бетеп килгән йортыннан кайтканда, кредит алу нәтиҗәсендә һәлакәткә очраган танышларны барладык һәм бурычсыз яшәвебезгә күрә бәхетле булуыбыз турында нәтиҗә ясадык.

Эльвира ВӘЛИЕВА

ӘГӘР БЕЛГӘН БУЛСАМ

ТУПЛАНМА ПЕНСИЯНЕ НИШЛӘТЕРГӘ?

Ерак әле... Пенсия турында сүз чыккач, бүген дөнья йөген җигелеп тартучы урта яшьтәгеләр әнә шулай дип кенә кул селти. Күпчелек тупланма пенсия турында да берни белми. Югыйсә ул күбебездә бар. Алай гына да түгел, тупланма пенсия кеше вафат булгач та юкка чыкмый, ди белгечләр. Киләчәктә коры пенсиягә генә утырып калмас өчен нишләргә? Тупланма пенсияне кайчан һәм ничек алырга мөмкин? Без әнә шул сорауларга җавап эзләдек.



freepik.com

«Үзе күчеп йөри»

Билгеле булганча, дәүләт тарафыннан картлык буенча түләнә торган пенсия ике өлештән тора. Болар – пенсиянең иминият өлеше һәм тупланма акча. Әнә шул ике күрсәткечне кушасың да, булачак пенсияң килеп чыга. Акчаның иминиятләштерелгән өлеше рәсми рәвештә эшләгән еллардан туплана. Шуңа күрә ул эш стажына һәм хезмәт хакы күләменә бәйле. Билгеле булганча, хезмәт хакының 22 проценты күләмендә акча Пенсия фондына күчерелә. Шунысын да искәртик: бу акча айлык хезмәт хакыннан тотылмый. Ул эш бирүче оешма хисабыннан түләнә.

2002 елда пенсия системасына яңалык керде һәм Пенсия фондына күчерелгән акчаның бер өлеше (16 процент) – иминият пенсиясенә, ә калганы (6 процент) тупланма пенсиягә китә башлады. Тик бу эш 2014 елда туктатылды. Гади тел белән әйткәндә, хәзер хезмәткәрләр өчен күчерелә торган акча алдагы кебек икегә бүленми, 22 процентның барысы да иминият пенсиясенә китә. Пенсиянең тупланма өлеше «катырылган» дигән сүзләр әнә шуннан чыккан да инде. Дөреслектә, бу акча юкка да чыкмаган, катырылмаган да. Илдә пенсиянең тупланма өлешенә мораторий гамәлдә. Федераль канун нигезендә ул 2025 елга кадәр озайтылды.

Ә моңарчы тупланма өлештә җыелган акча ни хәлдә? Баксаң, яшенә күрә пенсия турында уйларга ашыкмаучыларның күбесен бу сорау гомумән борчымый икән. Халык арасында үткәрелгән соңгы сораштыруда катнашучыларның өчтән икесе пенсиянең тупланма өлеше кайда саклануын, күпме икәнен белмәвен әйткән. «Бу хакта уйлаганым да юк. Ничәдер ел элек өйгә килеп бик үгетләгәч, тупланма өлешне исеме дә истә калмаган бер оешмага күчергән идем. Хәзер ул анда да түгел инде. Бер җирдән икенчесенә күчеп йөри. Ел азагында, пенсиягезнең тупланма өлеше фәлән оешмада, дип хат җибәрәләр. Аның күләме турында да кызыксынганым юк», – ди башкалада укытучы булып эшләүче Ләйсән Рәфыйкова.

Мәсьәләгә ачыклык кертүләрен сорап, Россия Социаль фондының Татарстан буенча идарәсе матбугат хезмәтенә мөрәҗәгать иттек.

ТУПЛАНМА ПЕНСИЯНЕ АРТТЫРУ ЫСУЛЛАРЫ

- Дәүләтнеке булмаган пенсия фонды белән килешү төзергә.
- Ана капиталын булачак пенсиягә салырга.
- Хезмәт хакыннан билгеле бер күләмдә акча күчереп барырга.
- Төрле финанслашу программаларында катнашырга.

– Гамәлдәге мораторий моңарчы җыелган акчаны төрле фондларга күчерү мөмкинлегенә берничек тә комачау итми. Тупланма өлештә җыелган акчаны нишләтергә икәнен һәркем үзе хәл итә. Пенсия акчасыннан аермалы буларак, тупланма өлеш дәүләт тарафыннан индексацияләнми. Аннан керем генә алырга мөмкин. Элек тупланма өлешне пенсиягә чыккач кына алырга ярый иде. Хәзер мондый мөмкинлек 55 яшь тулган хатын-кызларга һәм 60 яшь тулган ир-атларга бирелә. Дөрес, моның өчен тиешле шартлар үтәлергә, ягъни 28,2 шәхси пенсия коэффициенты һәм кимендә 15 ел эш стажы булырга тиеш. Суммасына карап, тупланма өлеш берьюлы (әгәр җыелган акча иминият пенсиясенең 5 процентыннан да кимрәк икән, ул берьюлы бирелә. – **Ред.**) яки өлешләп түләнә, – дип аңлаттылар идарәдә.

Җиде кат уйлыйсы

Тупланма өлеш турындагы мәгълүматны Социаль фонд яки Дәүләт хезмәтләре порталындагы шәхси кабинет аша алырга мөмкин. «ВТ» хәбәрчесенең тупланма өлеше, мәсәлән, бер дә ишетмәгән «Эволюция» Дәүләтнеке булмаган пенсия фондында булып чыкты.

Пенсия фонды белгечләре әйтүенчә, моңа әллә ни гаҗәпләнәсе юк. Бүген пенсиянең тупланма өлешенә бәйле алдау очраклары шактый икән. Кайбер кибетләрдә товарны кредитка алганда, пенсия акчасын Дәүләтнеке булмаган пенсия фондына күчерүне мәҗбүри шарт итеп куялар. «Алтын» пенсия вәгъдә итүчеләр ишек шакырга да мөмкин. Алдап-йолдап, тупланма өлешне ниндидер оешмага күчерергә үгетлиләр дә суга төшкәндәй юк булалар. Озын сүзнең кыскасы, документлар имзалаганда, шикле тәкъдимнәр алганда игътибарлы булырга киңәш итәбез.

– Дәүләтнеке булмаган пенсия фондларының үз сайтлары бар. Анда оешма турында бөтен мәгълүматны табарга мөмкин. Тупланма пенсияне дәүләтнеке булмаган фондка күчерү өчен, иң элек аның Иминиятләштерелгән затларның хокукларын гарантияләү системасына керү-кермәвенә (бүген әлеге исемлектә 28 Дәүләтнеке булмаган пенсия фонды һәм 12 идарәче оешма бар. – **Ред.**), эш тәҗрибәсенә һәм тупланма өлешне инвестицияләп күпме табыш алуына игътибар итәргә кирәк. Сезнең акча белән эш итүче оешма ошамый икән, икенчесенә күчәргә дә мөмкин, – диделәр Россия Социаль фондының Татарстан буенча идарәсенең матбугат хезмәтендә.

Тик бу эшнең дә җае бар. Булачак пенсияне арттырам дип, пенсиянең тупланма өлешен ел саен бер фондтан икенчесенә күчерергә киңәш ителми. Моны бернинди югалтуларсыз биш елга бер тапкыр гына эшләргә ярый. Югыйсә инвестиция керемнәре фондта калачак.

Дәүләтнеке булмаган пенсия фондларының Иминиятләштерелгән затларның хокукларын гарантияләү системасына керүе нәрсә дигән сүз? Оешма ябылган очракта, гарантияләү системасы Дәүләтнеке булмаган пенсия фондына күчерелгән тупланма өлешнең төп суммасын кире кайтару мөмкинлеген тәэмин итә. Ягъни фондка бирелгән акча югалмый. Ә менә инвестиция рәвешендә алган керем «яначак».

Иртәрәк кирәк

Тупланма өлеш кеше үлгәч тә юкка чыкмый. Рәсми мәгълүматларга караганда, узган ел Социаль фондның Татарстан буенча бүлеге вафат булганнарның 2,5 мең варисына 122,8 миллион сум (!) акча күчергән.

Мирас итеп күпме акча алырга мөмкин? Әлеге сорауга җавап эзләп, «ВТ» хәбәрчесе 1953 елда туып, пенсия яшенә җитмичә, 2008 елда вафат булган әтисенең тупланма пенсиясен белешеп карады. «Вафат булучының тупланма пенсиясе 2964 сум тәшкил итә. Тик якын кешегез үлгәнгә күп вакыт узган. Шуңа күрә иң элек суд аша тупланма пенсияне алу хокукын кире кайтарырга кирәк булачак. 3 мең сум акча өчен болай йөрү кирәкме?» – диделәр башкаладагы Социаль фонд бүлекчәсендә. Хәзер инде юк. Тик ул заман өчен аз акча булмаган ул. 2002 елда ипи 8 сум торган. Ә ил күләмендә уртача хезмәт хакы 4–5 мең сум тәшкил иткән. Нишләсәң дә, пенсияне иртәрәк уйларга кирәк...

«ГАРИЗАНЫ АЛТЫ АЙ ЭЧЕНДӘ ЯЗАРГА КИРӘК»

Эдуард ВАФИН, Россия Социаль фондының Татарстан буенча идарәчесе:

– Тупланма өлеш кеше вафат булганнан соң да юкка чыкмый. Аны алу хокукы кеше үзе исән вакытта язып калдырган гаризада күрсәтелгән кешеләргә бирелә. Мондый гариза булмаган очракта, закон буенча хокукый варислары булып туганнар санала. Беренче чирата – балалар, ир яки хатын, ата-аналар. Икенчесендә – абый-энеләр, апа-сеңелләр, бабайлар һәм әбиләр, оныклар. Алар, тупланма өлешкә бәйле түләүләр турындагы мәгълүматны белү өчен, туганлыкны раслаучы документлар белән Россия Социаль фонды бүлекчәләренә мөрәҗәгать итә ала. Шунысы да мөһим: моны кеше үлгәннән соң алты ай эчендә эшләргә кирәк. Югыйсә тупланма өлешне суд аша гына алырга мөмкин булачак. Әлеге тәртип бөтен кешегә дә бер үк. Махсус хәрби операциядә катнашкан вакытта вафат булганнарның варисларына гына кагылмый. Алар өчен тупланма өлешне сорап мөрәҗәгать итү вакыты чикләнмәгән.

Исегезгә төшерәбез: тупланма пенсия 1967 елдан соң туган кешеләрдә бар. 2002–2013 елларда рәсми рәвештә керем алулары шарт, әлбәттә. Әгәр эш бирүче 2002–2004 елларда тупланма өлешкә иминият кертеме түләп барган булса, тупланма өлеш 1953–1966 елларда туган ир-атлар һәм 1957–1966 елларда туган хатын-кызларда да бар. Пенсия тупланмасы акчасын алу өчен, Дәүләт хезмәтләре порталы аша Россия Социаль фонды бүлекчәләре яки Дәүләтнеке булмаган пенсия фондына гариза язарга кирәк.

Белеп торыгыз!

Бу елның 1 гыйнварыннан илдә озак вакытка исәпләнгән акча саклау программасы гамәлдә. Анда 18 яшьтән башлап теләге булган һәркем катнаша ала. Дәүләтнеке булмаган пенсия фонды белән килешү төзегәндә, беренчел кертем күләмен, аның вакытын һәм суммасын үзең билгелисең. Килешү ким дигәндә 15 елга төзелә. Ягъни түләүләр әнә шул вакыттан соң гына яки хатын-кызларга – 55, ир-атларга 60 яшь тулгач килә башлаячак. 2,8 миллион сумга кадәр җыелган акча иминиятләштереләчәк. Программага тупланма пенсияне күчерергә рөхсәт ителә.

БӘХЕТСЕЗ БУЛА АЛМЫЙМ!

Чаллыда яшәүче 28 яшьлек Аделина Миннәхмәтова сүзләре бу. Бер карасаң, сөйләшүендә кимчелеге булган, аякларын көчкә йөрткән, куллары тыңламаган ханымның тормыштан зарланып утыруы табигый булыр иде кебек. Тик бу аның кагыйдәсе түгел!

Табиблар аңа тугач та ДЦП диагнозы куя. Кызның тормышның якасына ябышканлыгы бала тудыру йортында ук күренә. Ул анда ук ничек тә яшәргә тырыша, бирешми. Гаиләдә абыйсы артыннан көтеп алынган кызчык һәркемгә кадерле була.

– Кимчелекләрем булса да, мин беркайчан да үземне башкалардан ким күрмәдем. Әллә үз дөньям шундый булды, әллә инде җиргә яратып яшәргә килгәнмен – әйтә алмыйм. Тик шуны беләм: мин беркайчан да «син авыру» дигән сүзне ишетмәдем. Әнә шул үзләре белән тигез итеп күргән кешеләр миңа яшәр өчен көч бирде, – ди Аделина. – Мин кечкенә вакытта әти белән әни аерылышты. Әмма бу мине бәхетсез итмәде. Алар икесе дә яңа гаилә корсалар да, безне яратулары шул килеш калды. Мине мәктәптән йә әни алыр иде, йә әтием.

Аделина эколог, психолог белгечлеге буенча укып чыккан. Чаллыда театр түгәрәгенә дә йөри. Тик утырмый ул. Әнә шул сыйфаты бәхетле иткән дә инде аны. Соңгы курста укыганда, төркемдәшләре белән сәяхәт итәргә барганнар. Шунда булачак ире Илмирне очраткан. Үзе әйтмешли, аңа кадәр күп еллар кияүгә чыгу турында хыялланган.

– Һәрвакыт, мин кияүгә чыгам, балалар үстерәм, дип әйтеп килдем. Моңа ышандым да. Гаилә кору теләгем зур иде. Үземә насыйп яр таба алмам дигән уйны башыма кертеп тә карамадым. Миңа кем карар дип тә борчылмадым. Психологка укыгач, тормышны башкача күрә башладым. Нинди генә сорауларым, проблемаларым булса да, үзем дә аларга киңәшкә барам. Шундук җиңел булып китә. Әчке дөньямны ишетә башлыйм, – дип сөйли Аделина.

Ә инде Илмиргә килгәндә, аңа – 42 яшь. Аның да физик мөмкинлекләре чикләнгән. Аделина әйтүенчә, иренең сөйләшүдә кимчелеге бик булмаса да, бер кулы тыңлап бетерми, аяклары да сиздерә.

– Үзебезнең авыру икәнне онытты инде без. Бәхетле булырга тырышабыз. Ә бит бар да безнең кулда. Моннан 1 ел да 2 ай элек безнең тормышыбыз тагын да түгәрәкләнде. Розалина исемле кызыбыз туды. Әни булырга җыенган мизгелләрдә кичергән рәхәт хисләрне, кулыма баламны алгач барлыкка килгән кичерешләремне әйтеп бетерер булмый. Һәр кызга әни булу бәхетен телим мин. Аеруча минем кебекләргә, – ди Аделина. – Баламны үз вакытында таптым. Табиблар ярып алдылар. Шөкер, сау-сәламәт балабыз туды. Беренче көннәрдә ничекләр карарбыз дигән идек, әниләребез ярдәмгә килде. Минем әнием дә, каенанам да бик булышты. Безнең өчен алар бик тырыша. Каенатам да яратып кабул итте. Балабызга да терәк алар.

Алар Аделинаның әнисе янында яшиләр. Илмирнекеләргә дә барып йөриләр. Икесе дә кызлары өчен өзелеп торалар. Берсе ашатса, икенчесе йоклата. Сабый да кечкенәдән яратуга күмелеп үсә. Хыяллары – үз фатирларын булдыру.

– Мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә киңәшем шул: күңел төшенкелегенә бирелмәгез! Хыял белән яшәгез. Ихластан теләнгән теләкләр кабул була, – ди Аделина. – Әгәр сукранып утырсаң, оят булыр иде. Әти-әниләребез исән-сау. Ирем янәшәмдә. Әни, дип кызым бөтерелеп йөри. Мин берничек тә бәхетсез була алмыйм. Һәр кешегә матур хисләр белән яшәргә насыйп булсын. Син яратсаң, сине тагын да ныграк яраталар!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ВТ | 2024 гаилә елы | И туган тел, и матур тел...

«Җылы оя»

БӘЙГЕ

50000 сум күләмендә 6 премия!

Гаилә ул – безнең оя. Ул – безнең тамырыбыз, канатыбыз, тормыш нигезе. Ныклы дәүләт исә ныклы гаиләләрдән җыела. «Ватаным Татарстан» газетасы Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе белән берлектә күркәм гаиләләрне барлау, җәмгыятьтә ата-ана абруен арттыру максатыннан, «Җылы оя» дигән зур бәйге игълан итә!

Матур, дус, тату гаилә сере нидә? Бала тәрбияләүдә нәрсә мөһим? Гаиләдә тел, милли үзенчәлек саклансын өчен нишләргә? Әлеге сорауларга ачыклык керткән үрнәк татар, чуаш, мари, мордва, удмурт гаиләләре турында язмаларыгызны көтеп калабыз, кадерле укучылар! Бәйге таләпләренә туры килгән язмалар «Ватаным Татарстан» газетасында һәм vatantat.ru сайтында басылып барачак. Җиңүчеләр декабрь аенда билгеле булачак һәм тантаналы шартларда бүләкләнәчәк.

БӘЙГЕ НОМИНАЦИЯЛӘРЕ

«КҮРКӘМ ГАИЛӘ»

Гаилә, гаилә кыйммәтләре, милли гореф-гадәтләр, көндәлек тормышта туган телнең роле турында иң яхшы язма.

I урын – 50000 сум
II урын – 30000 сум
III урын – 20000 сум

Татарстанда яшәүче чуаш, мари, мордва, удмурт гаиләләре турында иң яхшы язма – **50000 сум** (II, III урыннар каралмаган)

«ИШЛЕ БӘХЕТ»

Күпбалалы гаиләләр, шул исәптән тәрбиягә балалар алган гаиләләр, гаилә кыйммәтләре, милли гореф-гадәтләр, көндәлек тормышта туган телнең роле һәм милли кыйммәтләрне, туган телне буыннан-буынга күчерү әһәмияте турында иң яхшы язма.

I урын – 50000 сум
II урын – 30000 сум
III урын – 20000 сум

Татарстанда яшәүче чуаш, мари, мордва, удмурт гаиләләре турында иң яхшы язма – **50000 сум** (II, III урыннар каралмаган)

«БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК…»

8–11 нче сыйныф укучыларыннан үз гаиләләре турында иң яхшы язма.

I урын – 50000 сум
II урын – 30000 сум
III урын – 20000 сум

Татарстанда яшәүче чуаш, мари, мордва, удмурт гаиләләре турында иң яхшы язма – **50000 сум** (II, III урыннар каралмаган)

БӘЙГЕНЕҢ ШАРТЛАРЫ

- **«Җылы оя»** бәйгесенә язмалар **2024 елның 1 мартыннан 2024 елның 1 ноябренә кадәр кабул ителә.** Нигезләмә белән **www.vatantat.ru** сайтында танышырга мөмкин.
- Бәйгегә шигырь, поэма, хикәя-повестьлар, башка матбугат чараларында басылган язмалар кабул ителми. Язма күләме басма форматта, Times New Roman шрифты, 1,5 юл арасы белән 3 биттән артмаска тиеш. Материаллар **420097, Казан, Академия урамы, 2 нче йорт** адресына яки **konkurs_vt@mail.ru** электрон почтасына кабул ителә һәм кире кайтарылмый. Хатта авторның исем-фамилиясе, яше, торган урыны күрсәтелергә тиеш. Белешмә өчен телефон: **8(843) 222 09 70, 8917 927 00 40.**
- Бәйгедә катнашучының 2024 елның беренче яки икенче яртыеллыгына (кимендә алты айга) «Ватаным Татарстан» газетасына язылган булуы шарт, квитанция редакциягә язма белән бергә җибәрелә. (Исегезгә төшерәбез: һәр айның 15 нче числосына кадәр язылган очракта газета киләсе айдан килә башлый.)

Бәйгенең нигезләмәсе, тулырак мәгълүмат – **www.vatantat.ru** сайтында. Чара 2024 елның 1 мартыннан 2024 елның 30 декабренә кадәр дәвам итә. Оештыручысы – «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе. *Реклама* 12+

Игълан тактасы

Кемгә кирәк?

10–12 яшьлек кыз бала өчен җәйге күлмәкләр, туфлиләр бар.
Ләйсән. Мамадыш

12–14 яшьлек кыз бала өчен җәйге киемнәр бар. Кирәк кешеләр редакциягә мөрәҗәгать итсен иде.
Айгөл. Чаллы

5–6 яшьлек малай өчен спорт киеме бар. Шулай ук кышкы киемнәр дә бирә алам.
Миләүшә. Казан

Яхшы хәлдәге, бернчә тапкыр гына киелгән 44–46 үлчәмле кышкы тун, 36–37 үлчәмле язгы-көзге аяк киеме бирәм.
Гөлфия. Казан

Кемдә бар?

5 яшьлек малай өчен киемнәр алам. Бигрәк тә көзге, кышкы киемнәр булса иде.
Ләйсән. Казан.

Ир-ат өчен 43 үлчәмле аяк киемнәре, 48–50 үлчәмле өс киемнәре кирәк.
Ләйлә. Арча районы

Хәбәрләшү өчен **8 (927) 438-56-13** телефонына шалтырата аласыз.

«ТАМЫРЛАРНЫҢ НЫГЫГАН ЧАГЫ»

Хәзерге җырчылар да, җырлар да истә калмый. Моның сәбәбе нәрсәдә соң? Татарстанның халык артисты, мөгаллим Римма ИБРАҺИМОВА әлеге сорауга ачыклык кертте. Аның белән татарның асылын ачкан җырлар, милли тәрбия, шәхес өчен гаилә әһәмияте хакында да сөйләштек.

© Анна Арахамия / syuyumbike.ru

:: Римма апа, язмышыгызда хәлиткеч мизгел дип кайсын атар идегез?

– Очраклы рәвештә конкурска эләгеп, шуның нәтиҗәсендә Мәскәүгә – Бөтенроссия эстрада остаханәсенә юллама алу – тормышымдагы хәлиткеч мизгелләрнең берседер. Ул чакта мин – мәктәпне тәмамлап, КФУның тарих бүлегенә укырга керергә хыялланган гап-гади бер авыл баласы. Юкса бит беренче имтиханны да «бишле»гә биргән идем, икенчесенә килсәм, документларың юк, диделәр. Шулай итеп имтиханга керә алмый калдым. Әти-әни арттан йөрми, кая барып бәрелергә, кемнең ишеген шакырга да белмим. Ярый әле иптәш кызларым ярдәмчел булды, бөтенләй сыгылып төшәргә ирек бирмәделәр. Шуннан эшкә урнашырга, икенче елга тагын бәхетне сынап карарга булдык. Инде эшкә урнашкач кына, кызлар татар филармониясендә Мәскәүдә уку өчен конкурс барганын ишетеп кайтканнар. «Син бит матур җырлыйсың, барып кара әле, синең урының заводта түгел», – диделәр. Үзебезнекеләр һәм Мәскәү белгечләре каршында җырладым, үттем. Шулай итеп 12 кеше Мәскәүгә укырга киттек. Әллә ни аһ итмәсәк тә, шатландык, билгеле.

:: Әгәр татар артистларын Мәскәүнең эстрада бүлегендә укыту оештырылмаган булса, эстрада нинди эздән киткән булыр иде икән?

– Филармониянең сәнгать җитәкчесе Мәхмүт Нигъмәтҗанов новатор булган дип уйлыйм мин. Күрәсең, яңа сулыш, икенче караш кирәклеген сизенгәндер ул. Иҗат бер эздән генә барса, торгынлык башлана, шуңа аңа дулкынлану, эзләнү кирәк. Безне укытып кайтару – шул эзләнүнең нәтиҗәсе инде ул. Без Мәскәүдән үзебезнең җырлар, тулы бер образ, әзер костюмнар белән кайттык. Башта Казанның Спорт сараенда зур концерт куйдык. Халык бик яратып кабул итте. Анналары төркемнәргә оешып, төрле җирләргә таралып эшли башладык. Мин Зиннур Нурмөхәммәтов, Клара Хәйретдинова белән бер төркемдә идем. Күпмедер вакыт үткәч, үземнең төркемне оештырдым. Татарстан авыл-шәһәрләре, чит төбәкләрдә гастрольләр башланды. Заллар шыгрым тулы була иде.

:: Хаталанган чаклар булдымы?

– Сәхнәгә чыгып басуга, залда нинди тамашачы утырганын аңлау, аны тою тәҗрибә белән килә. Менә шул сизгерлек чарланганчы төрле хаталар да булгалый. Әйтик, укудан кайткач, безне Зиннур Нурмөхәммәтов белән Магаданга җибәрделәр. Җир чите бит инде, монда интернациональ җырлар кирәктер, дибез үзебезчә. Шыгрым тулы зал, концертны башлап, русча җырлый башладык. Халык: «Без татарча җыр тыңларга килдек!» – дип, йодрык болгап кычкыра башлады. Шунда ук татарчага күчеп, бөтен белгән җырларны башкардык. Аншлаг белән дүрт концерт бирдек.

:: Тамашачы күңелен ничек яулап алырга?

– Бөтен күңелеңне биреп җырласаң, тамашачы да синең белән җыр дөньясына чума. Ул синең белән җырда «яши». Моның өчен бөтен шартын туры китереп, дөрес итеп җырлау гына җитми, көчле энергетика, хис һәм белем кирәк. Ни өчен белем дим, еш кына җырчылар нәрсә җырлаганын аңлап җырламый. Үзең аңламаган нәрсәне халык та аңламаячак бит инде.

:: Хәзерге җырчылардан кемнәрне тыңлыйсыз?

– Алар шундый күп хәзер, кайсын тыңларга да белмәссең. Соңгы вакытта Филүс Каһиров өчен шатланам. Концерты шыгрым тулы залда үтте, халыкның аны яратуы сизелеп тора. Талантлы, тырыш егет.

:: Үзегезнең кумирларыгыз кемнәр иде?

– Кечкенәдән Әлфия апа, Илһам абыйларны тыңлап үстек. Безнең авылга концерт белән килсәләр, кечкенә генә клубка халык сыймый иде. Тәрәзә аша кереп, эскәмия астына качып булса да тыңларга тырыштык. Соңыннан, еллар узгач, бергә эшләү насыйп булды. Алар бик гади, ярдәмчел иде. Беркайчан да авылдан чыкканнарын онытмадылар. Илһам абый беренче концертларны оештырганда бик ярдәм итте. Без аның артыннан йөрдек инде, ул киңәшләрен кызганмады. Илһам абый – бөтен татар дөньясын уяткан кеше.

> Сәхнәгә ни өчен чыкканыңны аңларга кирәк. Тамашачы ул көзге түгел, аңа алдыңны-артыңны күрсәтеп, боргаланып тору гына җитми. Аңа тавыш мөмкинлекләрен күрсәтү генә дә җитми. Фикер җиткерергә кирәк. Шулай булмаса, бар да вакытлыча.

:: Татар милләтенең асылын ача торган төп 3 җырны атыйк әле.

– Халык җырлары. Илһам абый Шакиров репертуары. Анда безнең тарих, горурлык, шул ук вакытта югалту ачысы, сагыну. Әйтик, «Ак калфак» җырын алыйк. Аның берничә мәгънәсе бар. Шуларның берсе болай. Динен алмаштырырга теләмәгән татарларны шәһәрдән читкә куганнар. Әмма елга бер мәртәбә аларга калада калган туганнары белән очрашырга мөмкинлек бирелгән.

«Җитмеш чакрым якын җир түгел,
Бер күрешер өчен килдек без...»

«Су буйлап», «Җаныем-җанаш», «Гөлҗамал»... Безнең мирасны өч җырга гына сыйдырып бетерә торган да түгел. Ә инде дөнья буйлап сибелгән татарларны берләштерү җыры – «И туган тел...»

:: Соңгы вакытта «бетәбез» дигән фикер ешрак яңгырый. Ә сез нинди фикердә?

– Соңгы вакытта миндә, киресенчә, бетмибез дигән фикер ныгыганнан-ныгый бара. Яшьләрне күзәтергә яратам. Хәзерге буында милли үзаң көчле. «Без – татар» дигән горурлык бар аларда. Элек бит татарча сөйләшергә оялалар, вата-җимерә булса да русча җавап бирергә тырышалар иде. Хәзер чатнатып татарча сөйләшәләр. Студентларның берничәсендә генә булса да, киемнәрендә нинди дер милли билге була. Я милли бизәкле яулык, я каптырма. Шуны күргәч, күңелләр күтәрелеп китә. Ә бит рухланырга бер чаткы җитә. Әнә балалар өчен «Апуш» театр хәрәкәте барлыкка килде. Минем оныкларым да йөри анда. Татар даирәсе бит инде бу. Кабан күле янында яшәгәч, Камал театры тирәсеннән йөреп керү гадәтем бар. Яр буенда татар күйләре яңгырап тора, шулкадәр рәхәт. Җитәкчеләрнең дә милли темага игътибары зур, Рәисебез дә – бу җәһәттән үрнәк. Әле күптән түгел Казанга Владимир Путин килеп, Татарстанны мактап китте. Бу да милли горурлыкны ныгытырга зур сәбәп инде. Шуңа күрә, юк әле, бетмибез без. Тамырларның ныгыган чагы.



:: Милли тәрбия гаиләдәнме, мәктәптәнме?

– Гаиләдән дә, мәктәптән дә. Бала гаиләдә татарча сөйләшеп, мәктәптә башка мохиткә эләксә, тел югала. Хәзер мәктәпләрдә татар мохите тудырырга тырышалар һәм татар теле дәресләрендә балалар, чыннан да, телне белеп чыга. Элек татар теле дәресләренең вакыт үткәрүгә генә корылган чаклары да бар иде. Хәзер телгә кызыксыну бар һәм ул кызыксыну югарыдан башланды. Без – шундый халык: җитәкчеләр әйткәнне үтәп яшибез. Җитәкче үрнәк күрсәтә икән, халык та теленә игътибарлы була.

:: Гаилә дигәннән. Элекке артистлардан я сәхнә, я гаилә: икесен бергә алып барып булмый дигән фикерне ишеткән бар. Ничек уйлыйсыз, бу – дөрес фикерме?

– Эшкә яки иҗатка фанатларча табынырга кирәкмидер, миңа калса. Адәм баласының төп бурычы – нәсел дәвамчыларын калдыру лабаса. Синнән соң нәселең кала һәм эшең кала. Без ирем белән студиядә укыганда таныштык. Ул бер авыз татарча белми торган, Украинада туган татар егете иде. Мәскәүдә безнең белән бергә укыды, аннан Казанга татарча өйрәнергә кайтып китте. Без Казанда кавыштык. Татарча да өйрәнде, бергә яшәгән 25 ел гына азрак булды... Адәм баласына гаилә кирәк. Гаилә – канат, терәк бит ул.

:: Тормышымның горурлыгы дип кемнәрне яки нәрсәне атар идегез?

– Монда, әлбәттә, эшләгән эшеңне сөйләргә кирәктер. Ә минем горурлыгым – балалар. Алар йөземне кызартмады, шөкер.

:: Һәр татар укырга тиеш дип кайсы китапларны әйтер идегез?

– Тукай әсәрләре балачактан күңелгә салынырга тиеш, дип уйлыйм. Мин аның шигырьләренең күбесен яттан беләм. Тарихны күзаллау өчен, Нурихан Фәттах әсәрләрен укырга кирәк. Анда фольклор байлык та бихисап. Хәзерге заман әдипләреннән Ркаил Зәйдулла әсәрләрен яратып укыдым.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ЫШАНУДАН ТУКТАМА!

КХЛда Гагарин Кубогы өчен көрәш башланды. Былтыр финалга барып җитә алган «Ак барс»тан быел ни көтәргә? Сезон дәвамында җанатарларын еш борчыган Зиннәтулла Билалетдинов командасы плей-оффта нинди уен күрсәтер? Төп фаворит кем? Тамашачылар нәрсә өмет итә? Шул сорауларга җавап табарга тырыштык.

ak-bars.ru

«Ак барс» даими чемпионатны 4 нче урында тәгәлләде. Финанс мәсьәләсендә КХЛда иң хәллеләрдән саналган команда өчен артык мактанырлык нәтиҗә түгел. Әмма сезон уртасында эшләр тагын да начаррак иде. Команда бер мәлне хәтта плей-офф зонасыннан да төшеп калды. Танылган хоккейчылардан тупланган «Ак барс»та аларны ничек уйнатырга белми аптырадылар. Яңа елдан соң Казан командасы үзенә хас булганча чыгыш ясарга тырышты.

Мантыйк мондый: төп игътибарны саклануга бирәбез, ә һөҗүмдә оста егетләр үз алкасын кертми калмас әле.

Плей-оффта да шулай булачак. Төп бурыч – нәтиҗә, матурлык икенче урында. Ләкин узган ел финалга кадәр барып җиткән «Ак барс»та проблемалар да җитәрлек. Зиннәтулла Билалетдинов командаларында сакчылар уенына һәрвакыт өстенлек бирелде. Ә быел артыгын мактап булмый. Иң җаваплы чакта ышанычлы булырлармы? Икенчедән, һөҗүмдә төп эшне башкарачак беренче өчлек юк. Капитан Александр Радулов соңгы очрашуларда уйнамады, Вадим Шипачевның иптәшләре еш алмашынып торды, төп һөҗүмче булырга тиешле Дмитрий Яшкинның инде күптән бозга чыкканы юк. Соңгы вакытта «Ак барс»та иң яхшысы булып Кирилл Семенов, Семен Кошелев һәм Станислав Галиев өчлеге саналды. Әмма Гагарин Кубогы өчен көрәшкән командaны алар гына тартып бара алмаячак. Кыскасы, «йолдыз»ларга уанырга вакыт. Кирәк чакта Артем Лукоянов һәм башкалар да үз эшләрен башкармый калмас.

Төп өмет – бабалары Билал исемле булган ике кешедә. Беренчесе – Зиннәтулла Билалетдинов. Баш тренер плей-оффта кемне ни эшләтәсен яхшы белә, тәҗрибәсе җитәрлек. Икенчесе – Тимур Билалов. Лигада ул иң яхшы капкачылардан санала һәм моны плей-оффта да расларга тырышачак.

«Ак барс» беренче раундта плей-оффта иң аз алка керткән командаларның берсе «Автомобилист»ка каршы уйный. Акча мәсьәләсендә авырлык күрмәсә дә, Екатеринбург командасы үз тарихында нибары бер мәртәбә икенче раундка уза алды. Иң яхшы һөҗүмчеләре Стефан Да Костаның хәлиткеч очрашуларда югалып кала торган гадәте бар. Быел көндәшләр даими чемпионатта 4 мәртәбә очраштылар, 3 уенда безнекеләр җиңде.

Кыскасы, «Ак барс»ның «Автомобилист»тан өстен чыгасын фаразларга җөрьәт итәбез. Ә менә аннары ни булыр? Киләсе көндәшне фаразлау быел тагын да авыррак. Чөнки икенче раундта ике конференциядәге командалар бер-берсенә каршы уйный. Әйтик, Көнбатыштагы беренче команда Көнчыгышта дүртенче булганы белән очраша. Икенче – өченчегә, өченче – икенчегә, дүртенче исә беренчегә каршы уйный. Шулай итеп, «Ак барс»ның икенче раундта Мәскәү «Динамо»сы белән очрашу ихтималы бар. Фаразлар ясарга иртәрәк, әмма бу команданың даими чемпионатта җиңгәнен һәм Гагарин Кубогы өчен көрәштә төп фаворитлардан берсе саналганын истә тоту артык булмас.

Рөстәм МИҢНЕХАНОВ, Татарстан Рәисе:
– Даими чемпионатта булганнарны онытыгыз. Хәзер барысы да яңадан башлана. Сезнең алда бернинди киртәләр юк, бары җиренә җиткереп уйнарга гына кирәк. Без – сезнең тугры җанатарларыгыз. Команданың уңышлары да, проблемалары да безнеке. Без һәрвакыт сезнең белән. Иң мөһиме, имгәнүләр булмасын. Сезнең өчен Татарстанда гына түгел, республикадан читтә дә җан аталар.

(«Ак барс» уенчылары һәм тренерлары белән очрашуда сөйләгәннәрдән)

Гөлфизә КАМАЛИЕВА,
«Ак барс»ның иң өлкән җанатарларының берсе:
– 60 яшемә кадәр хоккейга исем китми иде. Очраклы рәвештә генә «Татнефть арена»га барып, матч карап кайттым да, шуннан башланды инде. Шул көннән соң бер генә матчны да калдырганым юк. «Ак барс» белән бергә читтәге уеннарга да йөрдем. Россия шәһәрләрен күрдем. Мине «Ак барс әбие», «тетя Галя» дип йөртәләр. Хоккейчыларны бик яратам. Алар миңа улларым кебек якын. Коронавирус чорында уеннарга йөреп булмады. Хоккей карар өчен, яңа телевизор сатып алдым. Әмма телевизордан карау икенче инде ул. Зиннәтулла Билалетдинов киткәч, бик моңсу булган иде. Әле клубның җитәкчелегенә: «Җибәрмәгез», – дип ялварып йөргәнемне хәтерлим. «Бәйләп куеп булмый бит аны», – дип көлгәннәр иде алар.

Гөлназ ГАТИНА,
«Татар кызы-2017» халыкара конкурсы җиңүчесе:
– Хоккей – иң мавыктыргыч спорт төрләренең берсе. Анда тизлек тә, хисләр дә – барысы да бар. Матчларны калдырмаска тырышам. Һәр уенның үз мохите бар чөнки. Әйтик, «яшел дерби» булса, бөтенләй башка рух хөкем сөрә, «Нефтехимик» белән бозга чыксак, дуслык атмосферасы сизелә. Соңгы елларда плей-оффның ахыргы уеннарыннан күз яше белән кайтып китәргә туры килә. Яраткан уенчым – әлбәттә, Данис Зарипов. Мин аның белән шәхсән күрешкәч, шатлыктан елап кайтканым истә. Хәзерге составка килгәндә, Дмитрий Кагарлицкий, Илья Сафоновны яратып күзәтәм. Капкачыбыз Тимур Билаловка аерым мәхәббәт белән җан атам. Әле бит хоккей яратуымны белепме, туган көнемә «Зарипов» дип язылган һәм 25 саны төшерелгән махсус джерси (хоккейчыларның өс кием. – **Авт.**) бүләк иткәннәр иде. Һәр уенга шуны киеп йөрим.

Әмир ЖУМАКАЕВ,
«Ак барс»ның иң яшь җанатарларының берсе
Әнисе Алинә:
– Улыбызга – 11 яшь. Хоккейны бәләкәйдән үз итә. Сөйләшә белми иде әле, әмма кулында кәшәкәсен нык тотты. Минем ирем дә – һәвәскәр хоккейчы. Әмир «Ак барс» уеннарына 5 яшеннән йөри. Гел трибунага барып булмый инде. Өйдә генә җан атарга туры килгәндә, барыбыз да махсус киемнән булырга тиешбез. Бу – шарт! «Ак барс»ның атрибутикасы өчен өебездә махсус почмак та бар. Әмир анда барлык шарфларын, кепка, плакат, кәшәкәләрен урнаштырып бара. Гагарин Кубогын дүртенче мәртәбә яулый алсак иде. Әмир моңа бик ышана! Аның кумиры – Данис Зарипов.

ТӘРТИП БУЛСЫН



Зиннәтулла БИЛАЛЕТДИНОВ, журналистлар белән очрашып, команданың плей-оффка әзерлеге хакында сөйләде.

Плей-оффка әзерлек турында

Плей-офф якынлашкан саен команда яхшырак чыгыш ясады, кемнең кем белән уйныйсы аңлашыла башлады. Февральдә яхшырак уйнаганбыз икән, димәк, хаталарны төзәтә алганбыз. Команданың кәефе яхшы. Егетләр соңгы очрашуларда начар уйнамады, без куйган бурычларны үтәделәр.

Көндәш турында

Алар төп игътибарны саклануга бирә дип әйтмәс идем, һөҗүмнәре дә яхшы. Уенчылары күбрәк чакта яхшы уйныйлар, азрак калганда уйнау буенча алар – лигада иң яхшы команда. Даими чемпионатта өч тапкыр җиңдек, дисезме? Хәзер инде моның әһәмияте юк. Җайлы көндәш түгел, плей-оффта андыйлар булмый да. Кыскасы, әзерләнергә кирәк. Хаталар азрак булган саен яхшырак. Дөрес итеп, тәртип белән, тырышып уйнарга кирәк.

Лидерлар турында

Александр Радулов 100 процентка әзер. Дмитрий Яшкин – мөһим уенчы, ул ныклап шөгыльләнә башлады инде. Үзенең нәрсәгә сәләтле булганын күрсәтү өчен бераз вакыт кирәк. Кайчан әзер булганын үзе хәл итәчәк.

1/8 финал уеннары

Көнбатыш конференциясе

Динамо (Мәскәү)
Динамо (Минск)

СКА
Торпедо

Локомотив
ЦСКА

Спартак
Северсталь



Көнчыгыш конференциясе

Металлург
Амур

Авангард
Лада

Салават Юлаев
Трактор

Ак барс
Автомобилист

Илнар ХӨСНУЛЛИН,
Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Тормышта юл күрсәтүче
Тискәре
Аллегрова
Удмурт
Бизмән йөге
Он суы
11 сыйныфлы бина
...-тәяк
Ярты яртысы
Балык Бистәсе районы авылы
Татар балалар бакчасы
Тапталган (юл)
Исем
«... һәм Маргарита»
Сафагәрәй, Үтәмешгәрәй
Татарстан санаторие
9 нчы катка «такси»
Кулга бирү
Спорт җиһазы
«ВТ» Гыйлемхановы
Су белән чистарту
Төче түгел
Тупның читкә чыгуы
...-сәламәт
Әкияти ... тавы
Тавык токымы
Совет җырчысы Патрисия ...
Сүзне җилгә ...
9 Май күрке
Кушу-...
Җәя таягы
Алёна Апина продюсеры
Ауди төре
Кирәгеннән тыш артык
Нота
... Насыйри
Собчак
...-лоп атлау
Коммерциягә булмаган оешма
Тиле... орлыгы
Төс
Ярату
Горур кош
Пугачева
Аудару
ВАЗ-1111
Биокыр
Аны үтерер ташладылар
Шәрә рәсем
«Аннабель Ли» авторы
Теләгән аның итен ашаган
Тутый кош төре
«Собака на сене» герое
Аның күңеле балада
Вахит Алекперов ширкәте
Кайнагач борыны сызгыра
Намазга чакыру
Эш
«Поехали!» дигән
...-зыгы
Теләче р-ны авылы
Тау көтүчесе
Роддомнан чыккан сарык
Морза
Мизгел
Сала
Шаккаткыч
Җай
Уйлау аппараты
«Дакар» раллие йолдызы
Моң туганы



Сканворд җаваплары

Горизонталь: начар, Ирина, гер, вак, мәктәп, Бәләкәч, такыр, стенд, Риман, Каф, юу, лангшан, ташламау, Каас, ре, алу, ук, ТТ, лап, Иратов, егу, кара, наз, Фәхри, Анарда, Алла, По, ана, чәйнек, Мәһдиев, чабан, Юра, ыгы, Алан, би, мән, әкәмәт, Лилия.

Вертикаль: Бәкер, Каюм, елан, лифт, ара, парад, Ксюша, Нигъмәтуллина, аһәң, әче, аура, авыл, чирек, нам, азан, гамәл, ар, аут, лачын, ми, ришвәт, Лукойл, мәл, апара, бәти, маяк, НКО, Чагин, Ырга, бәрән, Ришат, Мастер, ню, хан, гипер, сау, Ока.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Беләсең килсә...

1 Капельдинер сүзе нәрсәне аңлата?
а) театрда билет тикшерүче;
б) кечкенә штангенциркуль;
в) рәттә беренче очучы кыр казы.

2 Хрущёвтан соң ил белән кем җитәкчелек итте?
а) Черненко;
б) Брежнев;
в) Андропов.

3 38 нче химик элемент:
а) стронций;
б) рубидий;
в) магний.

4 Лилия Муллагалиева кайсы районнан?
а) Актаныш;
б) Апас;
в) Азнакай.

Җаваплар: 1.а); 2.б); 3.а); 4.а).

Әз-мәз мәзәк

***

– Әйдәгез, сезгә грипптан прививка ясыйбыз.
– Ясый күрмәгез, доктор! Узган елны да бөтен отделда берүзем эшләдем.

***

Юлбарыс өйрәтүче Запашныйлар карьераларын башлаганда икеу түгел, алтау булган, диләр.

***

– Ничек инде «Кайчан тагын кияүгә чыгасың?» Әле яши генә башладым бит!

***

Бер куллы сыер савучы иртән иртәрәк тора.

***

– Тәк. Нинди фикергә килдек әле без?
– Нәрсә турында ул?
– Яңа ел белән...
– Сине дә.

***

Чәчтарашханәдә иң авыры – ярты сәгать үз йөзеңә карап утырып, депрессиягә бирелмәү.

***

– Әҗәтеңне кайчан кайтарасың?
– Гафу ит, авырлыклар килеп чыкты.
– Нинди авырлыклар инде ул?
– Түлисем килмәде.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән. Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758. Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 11293 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 224

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й. «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+